Кәүсәрия ШАФИКОВА
Рәфис МӨХӘММӘТДИНОВ

# Мәхәббәт өермәсе



*Кәүсәрия Шафикова*
*Рәфис Мөхәмммәтдинов*

# *Мәхәббәт өермәсе*

**Шигырьләр, җырлар**

КИТАП
Уфа
2007

УДК 821.512.145-1
ББК 84-5 (2 Рос=Тат)
Ш 29

**Шафикова Кәүсәрия, Мөхәммәтдинов Рәфис**

Ш 29 Мәхәббәт өермәсе: Шигырьләр, җырлар. Уфа: Китап, 2007. — 192 бит.

ISBN 978-5-295-04322-2

Кәүсәрия Шафикова белән Рәфис Мөхәммәтдиновның исемнәре әдәбият сөючеләргә күптән таныш. Язмыш сынавына бирешмичә, тәкъдир катылыгына баш имичә яшәүче көчле рухлы затлар алар. Әлеге китапка каләм осталарының төрле темаларга язылган шигырьләре һәм җырлары тупланды. Аларның барысын да якты хис, сүнмәс өмет, гүзәллеккә табыну, тормыш ямен күрергә, аңларга чакыру берләштерә.

ТП — 161/07

УДК 821.512.145-1
ББК 84-5 (2 Рос=Тат)

ISBN 978-5-295-04322-2
© К. Ф. Шафикова,
Р. Н. Мөхәммәтдинов, 2007

*Кәүсәрия ШАФИКОВА*





*Мин, Шафикова Кәүсәрия Фидаи кызы, Башкортстанның Яңавыл районы Исәнбай авылында, гаиләдә беренче бала булып дөньяга килгәнмен. Тугыз айдан тәпи йөреп китсәм дә, яшел урамыбызда йөгерә-йөгерә уйнап үсәргә насыйп булмады, полиомиелит авыруы аякларыма басып йөрмәслек итте. «Авыртуларга да, кайгы-хәсрәтләргә дә түзәргә була!» – дип кистереп әйтә алам, сынады мине тормыш, юк, сындыра алмады, елап түгел, җырлап яшим! Шигырьләр, нәсерләр, хикәяләр яза башлавыма 30 еллап, унбер күмәк җыентыкта, «Бу җырым синең хакта», «Күз яшьләрең – көмеш тамчы» дигән аерым китапларда күп әсәрләрем дөнья күрде. Минем сүзләргә язылган җырларны күренекле җырчылар башкаруы шатлыкларымны чиксез итә! Көннәрнең кояшлысы да, болытлысы да бар, бар да күңелемә тирән уелган. Үземне бәхетле итеп санийм, ялкынланып сөям, янып эшлим ич мин!*

# Шигырьләр

## *Теләк*

И раббым, байлык сорамыйм,
Кирәкми алтын тавың.
Гомер бир, күргәннәремне
Мин җыр итәрмен тагын.
Тормышта көрәшер өчен,
Булсын авырлыклар да.
Мул булсын әле җанымда
Өләшер шатлыклар да!
Юлларыма киртә куйма,
Үрләргә менеп җитим.
Елларымны балкып торган
Йолдызлар тиңе итим.
И раббым, гомер бир!

## *Сына*

Җил — көчле, колачың җитмәс
Агачлар шартлап сына.
Сынармынмы, калырмынмы, —
Сына син, тормыш, сына.

Нечкә сабаклы бер гөлмен,
Сына җилләрең белән.
Тамчы да курыкмыйм: мин бит
Якты кояшка үрелеп
Үсәчәгемне беләм!

* * *

Балачакта дәү әнием
Ятлатты күп догалар.
Еллар үтте, ә догалар, —
Онытылды шул алар!
Намазлыкка иелмәдем,
Ярлыкачы, я, Алла!
Шигырьләрем дога кебек,
Изгелектән ярала!

* * *

Балачакка кайтыр идем,
Уйнап арганчы гына.
Уйларымда кайтам да соң,
Уйлар ялганчы гына.
Кайтыр идем чынына!
Балачакка кайтыр идем,
Миләш өзгәнче генә.
Янып торган миләшләрдән
Төймә тезгәнче генә.
Их, кайтырга балачакка,
Әнкәем сөяр иде.
Сөяр иде, «Син бит минем
Шатлыгым!» — дияр иде.

Күге аяз балачагым,
Сиңа юллар өзелгән.
Син еракта, синсез еллар
Моң-җепләргә тезелгән!

* * *

Тәнемнең дә, җанымның да
Яраланган чагы бар.
Тән ярасы төзәлсә дә
Җан ярасы һаман әрни, —
Ул — гөлләргә яуган кар!

* * *

Минем дә бар ул күңелдә,
Җәйнең гөле, кышның бозы.
Мин дә бит шушы дөньяның,
Әй, бик күпне күргән кызы.
Бозы — шакшыларга!
Гөле — яхшыларга!

## *Чын күңелдән*

Композиторлар күбәйде,
Күңелләргә сеңеп калыр
Моң ишеткән юк күптән.
Төн. Күзләрем — Кош юлында,
Тәгәрәтеп елатырлык
Моң агылыр күк күктән.
Шагыйрьләр дә бик күбәйде,
«Вәт, язган!» — дип шатланырлык
Шигырь укыганым юк.

Үзем дә шагыйрә, бәлки,
Файдага булыр, йөрәккә
Кададым әле сүз — ук!

* * *

Җил генә түгел, бу — давыл,
Әнә бит, нинди көчле!
Давыл булып килде кайгы,
Сынарга минем көчне.
Күрмисез: кайгының аның
Кан чыккан ярасы юк.
Тешемне кыстым, җиңәрмен,
Бу хәлдә кайгы-давылның
Тынмыйча чарасы юк!

* * *

Сабырлыкны сары алтын, дисәләр дә,
Юк, алтынга тиңләмим мин сабырлыкны.
Алтынсыз да яшәп була, ә сабырлык!..
Сабыр итеп, җиңеп була авырлыкны!
Шуны белмим: кеше күпме чыдый икән?
Сабыр итә-итә яшәү арытадыр!
Бәлки әле, сулкылдаган йөрәгендә,
Тешен кысып яшәгәнгә, көч артадыр!

* * *

Төш күрдем: яраткан гөлем
Сап-сары булып кипкән.
Өндәге кебек, төштә дә
Югалту авыр икән!

Елап уяндым — гөл исән,
Җанда да бар да имин.
Юк әле, «Киләчәгемне
Күргәнмендер мин», димим.
Сөйгәнен югалтканнарның
Болыт каплый шул күген.
Саргайган гөл итеп берсен,
Төшемдә күрдем бүген!

* * *

Агачлар әле ямь-яшел,
Җәй уртасы шул әле.
Әй, күңелем, яфраклардай
Яшел генә бул әле.
Сагынсаң сагын, саргайма,
Боегып кала күрмә.
Чәчәкләрнең төсен җуеп,
Күзләргә барып кермә.
Былбыл талга бишек элгән,
Җырлы чагы дөньяның.
Төрле чагы бар дөньяның,
Утларын йоткан чакта да,
Җырларын от син аның!

* * *

Шагыйрьнең юк зуры, бәләкәе,
Юк, үлчәүләр булмый ялкынга!
Ул мәңгелек ялкын, мәңгелек моң,
Бер җанын ул телә мең кылга.
Шагыйрьләрнең юк ул картайганы,
Яз китерә алар бу җиргә.
Алар гашыйк, алар сөеп туймый,
Яшьлек белән алар гел бергә.

Шагыйрьләрнең булмый имансызы,
Ышанмасаң әйткән сүземә,
Йөрәкләрен тыңла шагыйрьләрнең,
Шагыйрьләрнең кара күзенә.
Шигырьләрен ятла дога итеп,
Җан ризыгы җый син үзеңә!

## *Курчагымны эзлим*

Нәни кызлар, сезнең яннан
Эзлим бала чагымны.
Телемнәргә телгәләнәм,
Сагындым курчагымны.
Бала чагым — чәчәкле ил
Калды, мин ерак киттем.
Оныттым бит: кайсыгызга
Курчакны бүләк иттем?
Юк, мин аны кире алмыйм,
Беләсем генә килә,
Курчагым кем беләгендә,
Әни булып кем көлә?
Бишек җыры көйли-көйли,
Эзләп йөрим курчакны.
Курчагымны гына түгел,
Бүләк иткәнмен ич, кызлар,
Сезгә кояшлы чакны!

## *Атлар чаба*

Болыннарда атлар кешни,
Арт сикертеп чаба алар.
Кичке йомшак җил куенында
Дулкын-дулкын ефәк яллар!

Җирдә тояк тавышлары,
Тыңлыйм тормыш җыры итеп.
Атлар турындагы уйлар
Бәгыремне ала өтеп.
Күрше бабай сөйли иде:
«Күрәчәкне бергә күрдек,
Чәчәк аткан яшь чак иде,
Атлар белән утка кердек!»
Печәнлекне таптый атлар,
Таптасалар — таптасыннар.
Болыннарда чапсын атлар,
Яу юлыннан чапмасыннар!

* * *

Ир баласы изрәп йоклый белгәндә,
Йокламады ана, инде таң да атты.
Ана кеше бүген ничек йоклый алсын,
Күрше йортка табут белән солдат кайтты!

* * *

Бетте инде тынычлыгың,
Улың — солдат.
Төн йокыңнан уянасың
Ничә кабат?!
Булсын иде бишектәге
Генә чагы.
«Йокла!» — диеп бер тирбәтер
Идең тагы.
«Уяу бул!» — дип дәшә бүген
Синең йөрәк.
Уяу солдат илгә кирәк,
Кирәк! Кирәк!

## *Авыл урамы*

Җырлап түгел шул, сүгенеп,
Урамнан үтә яшьләр.
Шул вакытта бабайларның
Күзенә килә яшьләр.
«Кемнәргә калды бит урам,
Туздык шул инде, туздык.
Без яшь чакта урамнардан
Гармуннар белән уздык!»
Уфтанулар, үпкәләүләр
Урынсызга буламы?!
Бабайларның егет чагын
Сагына авыл урамы!

## *Фаҗига*

Чәчәк исе килми искән җилдән,
Гөлләрдә дә юкмы тамчы сафлык?
Нишләгән бу тормыш, нәрсә булган,
Елмаерга калмаган бер шатлык!
Нишләвегез, әй, сез, гүзәл затлар,
Яздыгызмы әллә акылыгыздан?
Күкрәкләргә тулыр һава тынчу —
Хәмер исе килә хатын-кыздан!

## *Сөйләшү*

Үлем турында сөйләшмик,
Үлем боздан да салкын.
Үлем ерак булсын әле,
Килә күрмәсен якын.

Безгә әле җылы кирәк,
Сүнмәсен яшәү-ялкын!
Гомер юрап гөл утыртам,
Гөлем үрелеп үсә.
Кояшка үрелгән гөлне,
Кочып назлы җил исә.
Гөлләр кебек чәчәк атып,
Яшик әле без, яшик,
Шул турыда сөйләшик!

## *Ятим*

Елмаеп торган булса да,
Күзләрендә яшь күрәм.
Ул язмыш миңа ят түгел,
Аңлыйм, хәленә керәм.
Бәхетсезнең бәхетсезе —
Анасыз калган бала.
Анасыз бала тик кояш
Җылысы белән кала.
Кояшны да болыт каплый,
Ятимнең хәле авыр.
Ул гомер буе кайгылы,
Ул гомер буе сабыр!
Ул гомер буе сабыр!

* * *

Татар авылында туды,
Татар ата-анасы.
Тик, үзенең әйткәне юк:
Мин, дип, татар баласы!

Татарча ачылды теле,
Инде сөйләшә белми.
Татарча җыр да тыңламый,
Татар буласы килми.
Күзләренә карап торам,
Нидер сөйли, тыңламыйм.
Уйлыйм: адашкан юлыннан,
Ничекләр тартып алыйм?..
«О, боже!» — ди бит, әйтерсең,
Юк үзенең Алласы.
Саташып шулай озакмы
Йоклар татар баласы?

* * *

«Уйнаштан туган бала ул,
Анасы йөреп тапкан!» —
Кыерсытыла саф күңел
Гайбәттән, кара таптан.
«Уйнаштан туган икән!» — дип,
Сөйләп-сөйлиләр пыш-пыш.
Ачы телләләрең белән,
Ямең җуясың, тормыш!
Нигә гаепләргә аны,
Ул изге, ул ана бит!
Ак биләүдә газизләрдән-
Газиз булган бала бит!
«Йөреп тапкан, кемнән микән,
Ул балада кем каны?»
Гайбәтченең гел пычрактан
Ярала икән җаны!
Бала туган, якты дөнья
Шатланып кабул иткән.

Аңага да, балага да
Бәхет өчен шул җиткән!
Күкрәгенә кысып-кысып
Баласын сөя ана.
Мәхәббәттән яралган ул —
Сөюдән туган бала!

## *Бүгенге малайлар*

Күр, ничек малайлар
Батырлык яулыйлар.
Таш белән бәргәләп,
Күгәрчен аулыйлар!
Киләчәк көннәрнең
Хуҗасы бит алар.
Вәхшилек кулына
Каламы дөньялар?
Күгәрчен баласы
Чыелдый ояда.
Белмиме малайлар,
Ятимнең күз яше,
Каргышы төшүләр
Бар бит ул дөньяда!

* * *

Белеп торам, сизеп торам,
Сагынгансың шул инде.
Йөрәккәеңне канатма,
Берүк, сабыр бул инде.
Беләсеңдер, моңым таша,
Җыр язам, нишлим тагын?!
Минем дә синсез чагым!

* * *

Шатлыктан елаган кебек,
Кояшлы яңгыр ява.
Җан өчен җылы яңгырның
Бер тамчысы да дәва.
Гөлләр яңгыр көтә иде,
Инде елмая бар да.
Яннарыңа барам, кал син
Кояшлы яңгырларда!
Барам!

## *Башкорт егетенә*

Кураеңны тарт син, башкорт улы,
Чыксын әле моңың ургылып.
Сылукайга булган мәхәббәтең
Яңгырасын әле җыр булып.
Әй, курайчы егет, нечкә билең
Алларыңа төшсен биергә.
Күбәләккәй кебек җилпенсен ул,
Ямь-гүзәллек биреп бу җиргә!
Кыядагы бөркет көче белән
Күкрәгеңә кысып алырсың.
Бер суырып үпсәң, йөрәгенә
Гомерлеккә ялкын салырсың.
Кураеңны тарт син, башкорт улы,
Гел әзер бул даның сакларга.
Кураеңны бирмә ят кулларга,
Сөйгәнеңне бирмә ят ярга!

## *Давылдан соң*

Яфракларны, әй, өзгәли,
Давыл кызгана белми.
Агач бөгелә, тик сынмый,
Юк, бирешәсе килми!
Яраланып бетә агач,
Каерылып имгәнә.
Явызлык тынгач, кояшка
Үрелә башлый янә!
— Ничек исән калдың, тирәк?
Мин шундый җавап алдым:
— Авырлыкны җиңә белгән
Кешеләрдән ояндым!

## *Яшәү турында җыр*

Җил исә, ул каен кызын
Иркәләп исә микән?
Әллә җилләр каен бәгърен
Телгәли-кисә микән?
Җил исә, әй, ул җилләрнең
Ничә төрлесе исә!
Билләреңнән өзеп алыр,
Башыңны түбән исәң!
Каенда яшел толымнар,
Аларны җил үргәндер.
Дөнья бит, ак каенкай да
Назлангандыр, сызлангандыр,
Мин күргәнне күргәндер!

* * *

Сызгырып җилләрне чакырам,
Күктәге болытны кусыннар.
Чәчәкләр кояшны сагынган,
Алар да бәхетле булсыннар.
Кояшны сагынам, күңелнең
Күкләрен болытлар капласа.
Соң, ничек елмайсын ул кеше,
Эзләгән бәхетен тапмаса?!
Сызгырып җилләрне чакырам,
Тырышам кояшым чыкканчы,
Нурларга үрелеп өлгерәм,
Авырлык бөккәнче-екканчы!

* * *

Авылны рәсемгә төшерәм,
Күрсәтер матурлык бар анда.
Бар анда игенле басу да,
Бар анда чәчәкле ялан да.
Су буе, былбыллы тирәкләр,
Барсы да минеке, барсы да.
Барсы да минем моң — җәе дә,
Көзе дә, кышы да, язы да!
Рәсемгә төшерәм авылның
Кычыткан, әремен — һәммәсен.
Юлларым чакыра, китәмен,
Рәсемне каршыма куярмын —
Сагыну бәгырьне телмәсен!

* * *

Байлыгым бар, юк, ул байлык
Миллиондыр-фәлән түгел.
Беркөн килеп чынга ашар
Матур хыяллары белән
Мөлдерәп тора күңел!
Шушы байлык белән яшим,
Куркасым юк карактан.
Ходай мине талап алып
Булмый торган зур бәхеткә
Ия итеп яраткан!

* * *

Әнкәй әйткән истә генә:
«Түздем, түзәргә була.
Кайгы ни ул — кайгы инде,
Күзләргә яше тула,
Җанда әрни яра булып,
Дәвасы шул — сабырлык!..»
...Жиңәлми, җиңелә генә
Миңа килгән авырлык.
Әнкәй әйткән көн дә истә!

* * *

Сең(е)лемнең бүген туган көне,
Сең(е)лем туган, апа булганмын.
Ә шундый зур апа, сең(е)лемнән
Ел ярымга алдан туганмын!
Сең(е)лем тугач, бәби күрергә дип,
Күчтәнәчләр белән кергәннәр.

«Апа булдың!» диеп мине сөеп,
Күңелемә шатлык үргәннәр.
Сең(е)лемнең бүген туган көне,
Апа кеше булган көнем бу.
Әле генә курчак уйный идек,
Юк, төшемдә түгел, өнем бу:
Ак чәчләрен күрәм сең(е)лемнең,
Апасына инде сүз дә юк!
«Ак чәчләр ул — бары күргәннәр! — дим, —
Ерак әле көзгә, яшисе бар,
Тирәкләрдә әле яшел чук!
Гомер тирәгендә яшел чук!»

## *Бер сүз*

Берәүнең бер сүзе
Йөрәгеңне өтә.
Берәүнең бер сүзе
Күз яшеңне сөртә.
Шигырь язам әле,
Бер сүз әйтәм мин дә:
Кеше көчле! Әйе,
Нәкъ башкалар кебек,
Көчле мин дә, син дә!

* * *

Тәлгәш балан, көн буена
Тәрәзәмне шакыйсың.
Эндәшмисең, бары көзге
Ялкын булып балкыйсың.
Ботагыңда салкын яңгыр,
Яфракларың җил өзгән.

Түзәсең шул, минем юкмы
Кыенлыкларга түзгән?!
Башкаема төшкәннәрнең
Түзеп киләм барына.
Тиңлим язмыш ачыларын
Балан ачыларына.
Беләм, шуңа эндәшмисең!

* * *

Син бар чактагыдай үсми гөлләр,
Тәрбияләү җитми, — бик беләм.
Сине сагынам, әнкәй, сагынудан
Тал гөлләрем кебек бөгеләм.
Син бар чактагыдай түгел җәйләр,
Күз яшедәй яуган яңгыры.
Бүген туган көнең, тик бәйрәм юк,
Кайгыларның миндә авыры.
Син бар чактагыдай түгел күңел,
Анда кояш түгел, сагыш-моң.
Мин көрәштә, әнкәй, йөрәгемне
Гел канатып яшим, чаралар юк,
Иркәләүче юк бит синнән соң!

* * *

И ходаем, күпме гомер бирдең?
Озын гына булса ярар иде.
Ни күрсәм дә, аһ-зар еламыйча,
Сүнә белми һаман янар идем!
Зиратларда арта барган саен
Үз-үзенә кул салганнар кабере,
Кул-аяксыз гомер кичерсәм дә,
Арта бара миндә яшәү кадере!

## *Туган көнем*

Роберт Миңнуллин да кырык сигез яш
тулган көнне шигырь язган

Миңа да бит бүген кырык сигез!
Ике елдан иллем тулачак.
Җитмеш-сиксәннәргә җиткән чакта,
Кырык сигезме, әй, ул иллеме,
Бик чак кына сагындырачак!
Әле миңа кырык сигез генә,
Ә дигәнче илле булачак.
Иң шәп вакыт, булмас болай гына,
Сөю-ялкын гына түгел, җанга
Әллә нинди көчләр тулачак!
Күкрәктәге көчкә ышанам мин,
Төсен җуймас күңел гөлләре!
Һәм ышанам шуңа, шагыйрьләрнең
Карт чаклары булмас, булыр бары
Яңа җырлы туган көннәре!

## *Бирешмибез*

Авыртадыр тәнең, каенкаем,
Яраларың бигрәк тирән икән.
Яшел толымнарың җирдә ята,
Ботакларга балта тигән икән.
Кеше явызлыгы! И каенкай,
Әрнүләрең таныш минем җанга.
Әйтерсең лә, икебезне бергә
Рәнҗеттеләр, батырдылар канга!
Бирешмибез әле, бирешмибез,
Син җилләрдә шаулап яфрагың яр.
Минем дә бит әле ап-ак каен
Тузларына язар җырларым бар!

## *Юлга чыгам*

Туган йортым белән саубуллашам,
Бәгыремне телә сагышым.
Киткән саен авыр газап итеп,
Кичерәм соң кемнең каргышын?
Кем каргаган мине, «Туган җирдән
Аерылып ерак китсен! — дип, —
Сагынудан авыр җәзалар юк,
Өзгәләнеп гомер итсен!» — дип?
Каргыш түгел бит бу, минем язмыш,
Минем язмыш, минем күрәчәк!
Китәр юлга чыгам, шуны беләм:
Кошлар кайтыр язлар киләчәк!

## *Ак халатлы фәрештәләргә*

Көтмәгәндә үлем белән очраштым мин,
Менә-менә җитә соңгы минутларым!
Торып каламыни шушы якты дөнья,
Сүнеп каламыни инде җыр-утларым?
Юк, китәсем килми, зинһар, коткарыгыз,
Коткарыгыз газраилнең пычагыннан!
Ак халатлы — ак канатлы фәрештәләр
Тартып алды мине үлем кочагыннан.
Изгеләрдән изге җанлы врачларым,
Ак халатны юкка гына кимәгәнсез.
Кояш гөлгә яшәү бирә, сез дә — кояш,
Күрәсезме, мин елмаям, рәхмәт сезгә,
Бу дөньяга юкка гына килмәгәнсез!

* * *

Минем байлык — ике сандык,
Тик алар түгел сатлык.
Бер сандыкта кара кайгы,
Икенчесендә — шатлык!
Кайгылысы биктә торсын,
Шатлык сандыгын ачыйм.
Күңелләре боекларга
Гөрләтеп бәйрәм ясыйм.
Ышандырыйм: яңа көннән
Бәхетен көтсен бар да.
Беләм ич, бүген үксегән
Иртәгә балкып елмаер,
Миндә шатлыклар барда!

* * *

Ходай биргән гомерен яшәп,
Соңгы юлга китә кеше.
Булмый булмас яхшылыгы,
Булмый булмас яман эше.
Төшкә керер, инде аны
Өндә генә күреп булмас,
Яхшылыгы сагындырыр,
Яманлыгы — онытылмас!

* * *

Елау белән аваз салып,
Дөньяга килгән көнем!
Ерак калды язлар күптән,
Чәчәген атты гөлем.

Күзләрнең бер салкын көнен
Бәйрәмем итеп яшим,
Ялкынланып-янып сөям,
Олыгайган саен яшем.
Сагынып нигә эзләргә
Үткәннәрнең эзләрен?!
Миңа яшьлек бүләк итә
«Син яшь!» дигән сүзләрең!

## *Бөгелмим*

Әнкәй сөйли торган иде —
Тулгагы авыр булган.
Шатлык-кайгылары белән
Дөньяга бала туган.
Мин — шул бала, мин — шул шатлык,
Мин — шул кайгы, — белегез!
«Кайгыларны җиңгән кеше
Кайгы була алмый!» — диеп,
Әйтер, бәлки, берегез!

* * *

Бәхетсез булдым шул, диеп
Елаганны юатам.
Яшен сөртә, күңелендә
Якты өмет уятам.
Күзләренә карап әйтәм:
«Зур бәхет көтә сине!»
Киләчәктә шат елмаеп,
«Син чын көрәшче икән!» —
Дип әйтсә иде мине.

* * *

Иң матур сүзне син әйттең,
Иң ямьсезен әйтмәссең!
Бәхетле иттең син мине,
Юк, бәхетсез итмәссең!
Синең күзләргә ышанам,
Ялганлык күрмим анда.
Син дә якты күрәсеңдер,
Күземә караганда!

## *Яшибез әле!*

Син бар! Син булмасаң, ничек
Йөрәгем тибәр иде?
Суга сусаган гөл кебек,
Саргаер, кибәр идем!
Синең рәхәтеңдә яшим,
Синең газапка түзәм.
Иманым син, догам итеп,
Йөрәк сүзләрем тезәм.
Таудай иттең бәхетемне,
Әйтерсең, сөйгән кешем!
Яшибез әле, шигърият,
Янабыз әле, син минем —
Изгедән изге эшем!

## *Хыяллар яшәсен*

Язмышыңны сүгә-каргый,
Иреннәрең тешлисең.
Башны ташка орып булмый,
Шулай язгач, нишлисең?!

Йөгерсәң адашырсың күк,
Канатсыз очалмыйсың.
Дөньялар гизәлмисең син,
Күкләрне кочалмыйсың.
Уфтануларыңнан беләм,
Эчләрең тулы ялкын.
Әй, бу тормыш, нигә икән
Искән җиле дә салкын?!
Карашларың шундый уйчан,
Сөйләгәнең моң-зарлы.
Ялгыз кеше, бөтенләй үк
Сүнгән учак түгелсең лә,
Хыялыңда син парлы!
Хыялыңда син парлы!

## *Язам*

Бу тормышта матурлык бар, ямьсезлек бар.
Мин шуларны күреп, кулга каләм алдым.
Шигырь язам, ямьсезлек көл булсын, диеп,
Йөрәгемне дөрләп янган утка салдым.
Шигырь язам, елый-елый, көлә-көлә,
Күз яшьләрем ләйсән яңгыр булсын әле.
Теләгем бер: гөлләр үссен, бу дөньяга
Язлар яктылыгы гына тулсын әле.
Кичә яздым, бүген язам, иртәгә дә,
Шигырь булып туар тагын бер матурлык.
Ул матурлык булыр җанны газаплардан,
Өзгәләнеп әрнүләрдән юатырлык!

* * *

Әй, бу тормыш, суык җиле
Күңел гөлемә тиде.
Гөлләр терелде, дәвасы —
Синең сагыну иде!
Әй, бу тормыш, давылларын
Җиңәр көч сорый миннән.
Җиңәрмен, «Синсез яшәү юк!»
Дигән сүз булды синнән!

* * *

«Авылың матур түгел», — диде
Миңа берәү.
Аның сүзе җанкаема
Булды тетрәү.
Авыр итеп суладым да
Башым идем:
«Уенчыктай матур өйләр
Юк шул!» — дидем.
Сырлап-бизәп эшләнгән йорт
Юк ул бездә.
Йорт-җир — гади, гадиләр без
Үзебез дә!
Игән башым күтәрдем дә,
Әйттем сүзем:
«Матурлыкны нигә тыштан
Эзли күзең?
Әйдә әле, керик, бездә
Табыннар мул,
Гади йортның түренә уз,
Кунагы бул!»

Китте кунак: «Сезгә тагын
Киләм!» — диеп.
Авыл белән саубуллашты
Башын иеп!

* * *

Әле күпме генә яши,
Якты дөньяга килеп.
Матур уенчыкларына
Кулларын суза көлеп!
Гел матурлыкка омтылып
Яшәрме шушы кеше?
Кеше шул, туды да, әнә,
Уйларымны тирән уйды,
Чыкканчы ук сөт теше!

## *Ике исемле мин*

«Гади генә түгел синең исем —
Коръән битендәге сүрә ул.
Тап төшерә күрмә исемеңә,
Гүзәллеккә генә ия бул.
Ширбәтле вә татлы Кәүсәр чишмә
Тик оҗмахта гына агар, ди.
Су эчәр, ди, аннан изге җаннар,
Гөнаһсызлар, алар баш очында
Фәрештәләр канат кагар, ди!»
Курчак кына уйный идем әле,
Зурнәй миңа шулай сөйләде.
Чәчләремне тарап үрде, үзе
Белгән догаларын көйләде.

Көн-төннәрен санап елларымның,
Минем гомер алга атлады.
Мулла кушкан исемем — Кәүсәрия,
«Шагыйрә!» дип тормыш атады.
Насыйп булган шушы ике исем
Бик кадерле минем үземә.
Иманымны саклыйм каралардан,
Ике дөнья баккан күземә!

* * *

И көне дә көне:
Кояш, җиле талгын!
Мизгелләрнең алтын
Чагы җитте тагын!
Көзнең шушы көнен
Ничек моңсу, дисең?
Иркен итеп сулыйм
Бакчаларның исен.
Басу исе килә —
Их, тәме дә тәме!
Бу бит тиңсез бәхет,
Бу бит тормыш яме!
Алда әле көзнең
Суык яңгырлары.
Булсын, әйдә, аның
Суык яңгыр-кары,
Язга кадәр бары!
Әле урамнарда,
Бу шигырьле көзнең
Яфрак бураннары!

## *Изгелек*

*Җәүһәриянең якты истәлегенә*

Тере булып төшкә керәсең гел,
Кигәнең дә матур, үзең дә.
Елмаясың, ачык сөйләшәсең,
Кояш нуры балкый йөзеңдә.
Очрашабыз икән, дияр идем,
Чыгалмыйсың кайтыр юлларга.
Укымышлы әби эзләмимен
Күргән төшләремне юрарга.
Син — оҗмахта, шулай яхшылыкка
Үзем юрыйм күргән төшемне.
Авыр иде хәлем, су каптырдың,
Мәңгелеккә киттең, дөньялыкта
Хәтер саклый изге эшеңне!

* * *

Инде сабыр итә беләм,
Елаган чагым сирәк,
Давылларны басар өчен,
Тешне кысарга кирәк.
Бөгелә күңел гөлләре,
Елмаям, шулай кирәк!
Елмаю һич җиңел түгел,
Үксегән чакта йөрәк.
Бүген дә, төтеннәре юк,
Ут булып яна эчем.
Елмаям килер көннәрне
Кояшлы итәр өчен!

## *Яшәү*

Үткән төндә йокламадым
Бер минут та.
Тынгы табалмады җаным,
Көйде утта.
Өзгәләндем, телгәләндем,
Түздем чак-чак.
Газапларым мең генә дә
Булмый кайчак!
Төн йокламый шигырь яздым,
Дөрләп янып.
Бу бит минем яшәү, сине
Сөеп, сагынып!

* * *

Картлар йорты, син тагын да
Бер карчыкны кабул ит.
Яше дә бик олы инде,
Ялгызына авыр бит!
Түрен түгел, ишек төбен
Бирми аңа баласы.
Боз эретер кояш бар, тик
Бәгырь ташын эретерлек
Көчне каян табасы?!

## *Язмыш*

Яшәгән җире оҗмах бит,
Ишетмим зарлы сүзен.
Тик!.. Тәрәздән тышка баккан,
Юллардан алмый күзен.

Балакаен өзелеп көткән
Ана булмый, кем булсын!
Саубуллашып китте бала...
Анасына бүләк итеп,
Картлар йорты җылысын!

## *Төтен*

Кайгыларны утка ягып булмый,
Кайгы үзе сине утка сала.
Түзми генә кара газабына,
Җаның тулы сүнгән күмер кала!
Өй җылытыр өчен якканнардыр,
Күтәрелә күккә кара төтен.
Әллә ничә кайгы бергә янып,
Әйләнсә дә кара төтеннәргә,
Җуя алмас күкнең зәңгәр төсен.
Тешләр кысылган!

## *Моң*

Сагыну да җиңел түгел,
Газабы мең бит аның!

Тын калып тыңлыйм: бар бер моң,
Ерактан ишетелә.
Үткәннәрдән килә ул моң,
Бәгырьне телә-телә.
Айкала-чайкала шул моң,
Күңел дәрьясы булып.
Кала икән үткәннәрнең,
Кайгы түгел, шатлыгы да
Хәтер ярасы булып!

* * *

«Тәртипсез!» — ди торганнардыр,
«Авылдан бит!» — диләрдер.
«Сез» димим мин, «син» дип дәшә-
Гаепләп сөйлиләрдер.
Изге китап битләре дә
«Син» дип дәшә Ходайга.
«Син» дип эндәшә Кояшка,
«Син» дип эндәшә Айга.
Яратуымны әйтәм лә
«Син» дигән сүзем белән.
«Син мине үлемгә бирмә!» —
Диеп сөйләштем бүген дә
Дөньяның үзе белән!

* * *

Кызарып пешкән баланны
Алдым тәлгәшләп өзеп.
Тик, баланны төймә итеп,
Булмый җепләргә тезеп.
Әйтерсең, кызарган балан,
Кайгы күлендә йөзеп.
Бөртекләп-бөртекләп кабам,
Ачыларына түзеп!

## *Шатлыктан елый алмыйм*

Шатлыклар тау булып өелә,
Әнкәй юк, күрергә әнкәй юк.
Сулкылдап и үкси йөрәгем,
Атылган җаныма кара ук.
Әнкәй юк!

Шатлыктан әй, елый иде ул,
Күз яшен чык итеп гөлләргә.
Әнкәйнең шатлыктан елавын
Тиң күрдем кояшлы көннәргә!
Көн саен бер гүзәл эш кылып,
Көн саен елатыр идем дә,
Әнкәй юк, тау кадәр кайгылар
Күтәреп яшимен иңемдә!

* * *

*Наилгә*

Ишетелә илаһи моң,
Назлы җил җыр көйлиме?
Талгын тибрәлеп, гөлгә гөл
Мәхәббәтен сөйлиме?
Тау чишмәсе моңымы бу,
Җанга якын бигрәк тә!
Шатлык-сагышы — күңелдә,
Дулкыннары — йөрәктә!
Каян бу моң, асыл кошлар
Серләшәме талларда?
Юк ла инде, шундый аһәң
Каян булсын аларда?!
Моң түгелә! Тукта, бу бит,
Җырчы, җырчы! Тормыштагы
Бозларны эретүче,
Канатларым сынган чакта
Рухымны терелтүче!

* * *

Каеннан өзелгән яфрак,
Син минем моңлы җырым.
Җәйне кире кайтарырлык
Булса да йөрәк җылым,
Син бөре булалмассың шул,
Яшел чак үткән инде.
Яшьлек үткән, җанны телеп,
Мең сагыш өткән инде.
Көзге җилләр өзгән яфрак,
Юк, килмәс безгә язлар.
Тик миндә өмет сүнмәгән,
Яшел бөреле язларда
Мине юатыр наз бар!

## *Җиңәм*

Җил куенында сары яфрак,
Көз җитүе шул инде.
Күңелем кылларын чиртеп,
Җаныма моңы иңде.
Кошлар төркеменә карап,
Уйларга талган чагым.
Сагышка түзми бер җырлап,
Бер елап алган чагым.
Җиңәм көзләр моңсулыгын,
Язларга каршы барам!
Таллардан яфрак өзелә,
Мин яңа яфрак ярам!

## *Көз*

Җиле белән тәрәзәмә
Чиртә-чиртә әйтте көз:
«Болыннарга чәчәккә, дип,
Баралмассың, өмет өз.
Тургайларның тавышлары
Тынып калды кырларда.
Талларның да кошлары юк,
Җәйге моңнар тибрәлер тик
Күңелдәге кылларда!»
Тәрәзәдән тышка бактым,
Әнә ул, яшел басу!
Күкләре булыр тургайлы,
Таңнары булыр алсу!
Ямь-яшел уҗымлы көзләр
Ямьсез була аламы?
Тормыштан ямь китәме соң?!
Җан өметсез каламы?!

## *Сөю ялкыны*

Чәчәгем, дип дәшеп иркәлисең,
Чәчәк булсам мин бит сулырмын.
Ялкын минем җаным, сүнәр, димә,
Мин һәрвакыт тере булырмын.
Гади генә ялкын түгел миндә,
Җырлар туа шушы ялкыннан.
Миңа яшәү биргән ялкын бит ул,
Һәм ул сине саклый салкыннан!

## *Бүләк итәм*

Шатлык көтә кеше, үксеп-үксеп,
Шатлыгыннан килә елыйсы.
Күп кирәкми, бер шатлыкның кайчак
Гомереңә җитә җылысы.
Кайгы көтми беркем, ә ул килә,
Бозлар булып туңа бар җаның.
Кайгы авыр, сине гомер буе
Әрнетерлек көче бар аның.
Шатлыгым бар, кайгы-хәсрәтем бар,
Берсеннән дә мәхрүм түгелмен.
Кайгылыга бүләк итеп яшим
Бәйрәм иткән чагын күңелнең!

## *Җырлар дәвалый гына*

Җәя керешен тартасың,
Уең булмасын кара.
Угың кемдер йөрәгенә
Сала күрмәсен яра.
Кара аны, җәяң угы
Кошларга төзәлмәсен.
Ялгыз кошның карашлары
Күзеңә төбәлмәсен!
Нәрсә уйлап уклар юндың,
Сындырып ташласаңчы.
Уклар итеп йөрәгемнән
Җырларымны алсаңчы!

## *Матурлык эзлим*

Үз парларын табалмыйча,
Ялгыз уфтанучыларга
Димче булдым.
Яратышып яши-яши,
Бер-берсеннән бизгәннәргә
Имче булдым.
Битлек киеп йөргәннең
Йөзен ачтым, явызлыгын
Кылалмады.
Тик үзгәреш юк тормышта,
Нишләсәм дә, юк, минемчә
Булалмады!
Кул селтәмим әле, һаман
Көрәшергә бар шикелле
Минем көчем.
Барыбер, дим, табылачак
Ул матурлык, көрәшүем —
Тормыш өчен!

## *Кыз киткәндә*

*Айгөлгә*

Күрше авыл егетенә
Кыз озата авылым.
Теләк тели ак каеннар:
«Сез бергә пар канатлылар,
Бөгелми-сынмый җиңегез
Бу тормышның давылын!»
Аккошлар теккән, диярсең,
Кыз кигән туй күлмәген.

Кияүгә эндәшә гөлләр:
«Хыянәт белән таплама
Сөйгәнеңнең сафлык дигән
Иң кадерле бүләген!»
Кыз китә, авыл чишмәсе
Чылтырап әйтеп кала:
«Бәхетең зур булсын, дисәң,
Якты бул, тәмле телле бул,
Суымны эчтең, бала!
Суымны эчтең, бала!»

* * *

Ботакта бердәнбер яфрак,
Беләм, нигә өзелми.
Әйтәсе сүзен әйтмичә,
Дөнья куясы килми.
«Киләсе язлар бар!» — диеп
Әйтәсе килә аның.
Яфракның тавышын ишетәм,
Тормышның салкын тынына
Курылган чакта җаным.

* * *

Рәхмәт сиңа, миләшле көз,
Җырлап туймас җырым булдың.
Күңелемә балачагым
Матурлыгы белән тулдың.
Әнә, күрәм коңгырт күзле,
Кара чәчле бер кыз бала.
Кызның нәни учларында
Миләш ут булып кызара.

Муенында миләш-төймә,
И шатлана, үзе тезгән!
Ерактагы көзне сагыну
Күңелем кылын ничә өзгән?!
Йөзләремне нигә чытыйм,
Ачы түгел миләш, тәмле.
Көзләр моңсу, димим, көзләр
Хатирәләр белән ямьле!

* * *

Сүрәнләнеп калды кояш нуры,
Китәр юлга чыкты кошкайлар.
Күңел кылларымны чиртә-чиртә,
Елата шул мине бу айлар.
Үлән-гөлләр кибеп бетте инде,
Кар болыты йөзә күк тулып.
Бер күкрәккә сагыш тамчылары
Җыелган шул инде күп булып.
Бакчадагы кызыл миләшләрнең
Ачы тәмен инде мин беләм.
Кошлар кебек китәр чагым җитте,
Яфрак койган талдай бөгеләм!..

* * *

Тормыш-көнитмеш бакчамда
Бар төрле җимеш.
Күбесен өзеп ашадым
Бик ачы килеш.
Балланып өлгерә торган
Булмады алар.
Май аенда чәчәкләргә
Яуды шул карлар!

Җимеш бакчасына керсәм,
Уйларга талам.
Көн башлана гына, тормыш,
Бүген нинди җимешеңне
Авызга алам?

* * *

Кар катыш ява яңгырлар,
Гөлләр өши түтәлдә.
Күзләр куенында калган
Гөлләр түгелмен әл дә!
Мин — кеше, түзәргә була,
Ничә төрле салкынга!
Ышанам туңудан саклап
Калыр сөю-ялкынга!

* * *

Тирәкләр бәскә төренгән,
Тантана итә аклык.
Кыз балада — матур хыял,
Кыз күңелендә шатлык.
Туй күлмәге кияр әле,
Ходаем насыйп итсен.
Сөйгән яры ил чигендә,
Исән-сау кайтып җитсен.
Үксемәсен әле сөю,
Кайгы яшьләре ачы.
Табутта кайтмасын егет,
Дөнья, ак булып калчы!
Тирәкләр бәскә төренгән...

## *Ышанам*

Сабый йоклап яткан ак җәймәгә
Охшатам мин сине, беренче кар!
Бернигә дә тиңләп булмый торган
Синдә сафлык, синдә матурлык бар!
Кер кунмаган әле бер тамчы да,
Сабый күңелендәге аклык синдә.
Энҗе генә булып сибеләсең, кар,
Аклык синдә булса, шатлык — миндә!
Менә бүген кеше күңеленә
Тик изгелек иңә ала кебек.
Елмаялар, һәрбер елмаюга
Мин ышанам сабый бала кебек!

## *Туган телне белмәгәч...*

Күкрәгемә кысам яңа гына
Дөнья күргән шигырь китабын.
Минем җырлар анда, минем моңнар,
Шатлык тауларында мин тагын!
Тукта-тукта, шатлык таудай ла ул,
Тик, түгәрәк булып бетәлми! —
Сең(е)лемнән туган балаларга
Китабымны бүләк итәлмим!..

* * *

*Рәфискә*

Ап-ак карлы февраль ае,
Син мине өшетмисең.
Җилең-бураннарың белән
Үзәгемә үтмисең.

Яз яктысы күрәм синдә,
Синдә җәйге җылы бар.
Җем-җем бәсле тирәкләрдә
Һаман кошлар җыры бар.
Ак чәчәкләр булып көлә
Бүген яуган карларың.
Мәхәббәтем ялкынына
Әйләнде салкыннарың.
Әйтсәм әйтим: шушы көнне
Минем сөйгәнем туган!
Шуңа да, февраль, кочагың
Кояшлы гына көннәрнең
Ямьнәре белән тулган!

* * *

Матур төшме, әллә хыялмы бу,
Чынбарлык дип ничек ышанырга?
Тик икебез өчен чыккан кояш
Дөньябызны төреп алды нурга.
— Мин яратам сине!
— Мин дә сөям!
Ялкын булып яна ике йөрәк!
Әрнүләрең, димәк, бер басыла,
Бу тормышка ышанырга кирәк!

## *Алдану*

Кар яуганны көттем. Җирнең өстен
Ап-ак итеп килде күрәсем.
Калмый икән кайгы кар астында,
Котылу юк аннан, күрәсең!

Авыл зиратында карны көрәп,
Кабер казый ирләр бүген дә.
Бер кардәшем вафат, әле һаман,
Күңелемне алдап, ап-ак карлар
Бөтерелә гыйнвар күгендә.

## *Бүләгем*

*Рәфискә*

Кыш аенда болыннарда
Чәчәкләр өзеп булмый,
Дулкыннарны яра-яра
Күлләрдә йөзеп булмый.
Ә мин өзәм чәчәкләрне,
Кышлар булмый күңелдә.
Хис-дулкыннар ярып йөзәм
Мәхәббәтем күлендә.
Буранлы февраль аенда
Туган көнең, бәйрәмең!
Бүләгем итеп кабул ит
Сөюнең мәңгелек язын,
Бәхетле итәр ямен!

* * *

Элекке түгел иртәләр,
Элекке түгел кичләр.
Тик, һаман да элеккечә
Ялкынлы килеш хисләр!
Элекке түгел хыяллар,
Уйлар элекке түгел.

Тик һаман да матурлыкка
Мөкиббән минем күңел.
Элеккечә типми йөрәк,
Элеккечә күрми күз.
Тик, һаман да сиңа гына,
Пышылдап кына тик сиңа
Әйтелә шул бер үк сүз!..

* * *

Сүзләрем бар, ничек сөйлим?
Җил өзде бит элемтәне,
Җуелды да бетте кебек
Бу дөньяның бөтен яме.
Әй, телефон, шалтырачы,
Балкыт әле күңелемне.
Бәгыремә үтте бу җил,
Харап итте бер көнемне!
Әйтерсең лә, көн буена
Күрмәдем мин кояш йөзен,
Ишетмәдем сөйгәнемнең:
«Сагындым!» дип әйткән сүзен!
«Тапкан язар нәрсә!» диеп,
Бәлки кемдер миннән көләр.
Көлсен, аңа ят нәрсә бит
Минем язмыш, минем көннәр!

* * *

*Рәфискә*

«Дару эчмә!» — димә миңа,
Тәмен табып эчмим.
Сине ялгыз калдырмаска,
Дару эчәм ич мин!

Әрнетәсем килми сине,
Иртә әле, иртә!..
Чир җиңелә, даруларның
Әле көче җитә.
Шөкер! Якты иртәләрне
Каршылыйбыз бергә!
Син әйтәсең: «Дару түгел,
Мәхәббәтем саклый сине
Керүләрдән гүргә!»
Рәхмәт!

## *Бәйрәмеңә киләм*

Синең туган көнне котлап,
Явадыр бу ап-ак кар!
Җем-җем килеп яуган карның
Ак төсендә шатлык бар!
Ерак китсәләр дә, талга
Кунып сайраган кошлар,
Матурлык бетми, талларны
Ак бәскә төрә кышлар!
Бүген дә шундый гүзәллек,
Дөнья ак нур коена!
Яуган карның һәр бөртеге
Энҗе булып коела!
Иңнәремдә кар-чәчәкләр,
Кочып алырсың, беләм!
Юк-юк, кар аклыгы түгел,
Сөюнең ак чәчәкләрен
Бүләк итәргә киләм!

## *Көткән чак*

Шатлыклар күккә күтәрде,
Кайгыларым үксетте.
Үз дигәннәрем суынды,
Чит-ятлары үз итте.
Тәмамланып килә бу ел,
Калды бер генә көне.
Бар әле, бар, бер көне бар,
Бар бер караңгы төне!
Кичерешләрнең төрлесе
Килүе мөмкин әле.
Тик туачак Яңа елны
Көткән чак бу, өметләрнең
Иң-иң-иң якты мәле!

## *Кояшымны күрәм*

Буранда калган юлчының
Хәлләрен яхшы беләм.
Кояшны күрергә тели,
Һәм ул бара, буран яра
Якты өмете белән.
Буранда калган идем мин,
Бер түгел, әллә ничә.
Әй, хәтәр тормыш бураны,
Йөрәгеңне суырып алыр
Усал җилләре исә!
Буран! Кеше юлда, җаны
Канады инде ничә!
Кояшын күрә алырмы,
Юллардан яздырыр авыр
Язмышка башын исә?!

## *Синең өчен*

Тамчы тама, язгы тамчы,
Җанга наз булып иңә.
Нәни тамчы әнә шулай
Сагыш җилләрен җиңә!
Колакларны, әй, иркәли
Көмеш тамчылар чыңы.
Күңелдән таша хисләрнең
Ялганы түгел, чыны!
Синең өчен тамчыкайлар
Булып тезеләм әле.
Умырзая чәчәкләре
Булып өзеләм әле!

* * *

Җилләр булып истең
Назың-җылың белән.
Былбыл булып килдең
Моңлы җырың белән.
Яңгыр булып яудың
Күкрәүләрең белән.
Яшен-ялкыннарың
Күкрәгендә, беләм!
Чәчәк булып үстең,
Китмәс сөю, китмәс!
Минем сөю сине,
Синең сөю мине
Мәңге ялгыз итмәс!

## *Умырзая ачылган чак*

Апрельнең уналтысы, каргалган көн,
Миңа ачы кайгы булып килгән көн бу.
Күз яшемне күреп, мине көчсез, диеп,
Баш очымда бәхетсезлек көлгән көн бу.
Әйләнә дә килә бу көн, ничә еллар,
Йөрәгемне телеп үтә. Кеше чыдам!
Язларны яз итү кирәк — чәчәк булып,
Бу тормышның кар-бозларын
тишеп чыгам!

## *Ышаныч*

Мин үлгәч тә язлар килер
Ярсу ташкыннары белән.
Миннән соң да килгән җәйләр
Шау чәчәкле булыр, беләм.
Алтын яфрак сибәр көзләр,
Ак буранлы булыр кышы.
Бер шагыйрә туар, җырсыз
Булмас көне, аңа күчәр
Минем җанның сайрар кошы.

## *Сабантуйлар җитте*

Сабантуйлар җиткән саен
Күңелне сагыш сара.
Кулъяулыклар чиккән чакны
Онытып яшәп кара!
Матур итеп чигә идем,
Оста иде кулларым.

Бүләкләдем сабантуйның
Батыр дигән улларын.
Кулъяулыкка чигә идем
Чәчәкләрнең алларын.
Әле һаман җанда саклыйм
Шулчакның ялкыннарын.
Куллар гына энә тотмый,
Табарсың ни чарасын?!
Толым-толым, аллы-гөлле
Җепләрем дә бар да соң!
Булмый инде, яшь кызларга
Калдырам бу һөнәрне,
Алар чиксен кулъяулыкка
Яшьлектәге төсен җуймас,
Шиңә белмәс гөлләрне.

## *Башкортстан гөле мин*

Таң ата! Җирем өстендә
Уйный нур көлтәләре.
Иркәли җанны назлы җил,
Былбыллы иртәләре.
Туган җир булганга микән,
Яшел ул, шундый яшел!
Яшь үләндә чык җемелди, —
Әйтерсең, шатлык яше.
Һәр көнемне җырлы иткән
Туган җир назыдыр ул!
Ялкыннары сөюгә тиң
Туган як языдыр ул!
Башкортстан, синең изге
Туфрагыңда тамырым.
Тормышка ямь бирер, сулмас
Гөлең булып калырмын!

* * *

*Ләйсән белән Илнурга*

Ике аккош итеп күрәм сезне,
Зәңгәр күлдә йөзгән ике аккош!
Дөнья шундый күркәм, җирне, күкне
Тоташтырып тора сихри балкыш.
Якты күлдә дулкын, таң җиленә
Җилфер-җилфер килә камышлар да.
Юк, матурлык китми күл буеннан,
Бөтен сере аның аккошларда.
Аккош җаны белми салкын кышны,
Язлар белән яши алар гелән.
Аккош җаны белми хыянәтне,
Яши алар иң саф сөю белән!
Ике аккош итеп күрәм сезне!

* * *

Инә каз шул, бәбкәләрен
Канат астына алды.
Газизләрен җил-яңгырлар
Тиюдән саклап калды.
Моңым дулкынында йөзеп,
Җырыма керде казлар.
Өзепләр ала үзәкне
Әнкәйсез килгән язлар!

* * *

*Мәктәпне тәмамлаучыларга*

Мәктәп кала, очар канатларың
Ерак алып китәр, мөгаен.
Ак теләкләр генә теләп кала
Мәктәп янындагы ак каен.

Дәшеп тора гүзәл хыялларың,
Изге эшләр килә кыласың.
Килә синең батырлардан батыр,
Матурлардан матур буласың.
Кыңгыраулар чыңы яшәр синдә,
Үткән еллар моңы — ул чыңнар.
Төшләреңдә кереп сагындырыр
Кире кайтмый торган ул еллар.
Мәктәбеңнән чыккан юлың сине
Зур тормышка алып китәчәк.
Тик, исеңнән чыгармачы, бала,
Иманына тугрыларны гына
Кабул итә якты киләчәк!

* * *

Ясалма чәчәкләр саталар,
Матурлык күзләрне уйната.
Ясалма чәчәкләр ник әле
Күп нәрсә хакында уйлата?
Ясалма матурлык бар шул, бар,
Үз төсен, һай, бик тиз җуя ул.
Кызгана белми шул, җаныңны
Әрнетеп, яралар уя ул.
Ясалма дуслык бар, сөю бар,
Күз яше, елмаю!.. Я, Ходай,
Коточкыч! Кешеләр күңеле
Ясалма бизәкле ник шулай?!
Ясалма чәчәкләр саталар,
Сокланам останың кулына.
Әй, тормыш, ясалма чәчәкләр
Сипмә син тормышлар юлына!

## *Минем кайгы*

Мәңгелеккә килүләр юк,
Гомеркәйләр чикләнә.
Тагын берәү дөнья куйды,
Тагын бер йорт бикләнә!
Ыңгырашып яши авыл,
Хәл генә белүче юк.
Авылны үтермәс өчен,
Бишекләр әлүче юк!
Якты гүрләр тели-тели,
Авылны җирләрбезме?
Тоташ авылны ялмаган
Үлемне җиңәрбезме?..

## *Йокысызлык*

Төн үтә, кан даулап черки,
Безелди дә безелди.
«Ничек кума, мин барыбер
Каныңны эчәм, бел!» — ди.
Черкигә каршы дару бар,
Иртәгә сатып алам.
Вәхшилеккә ни чара бар?
Уйларым дөнья әйләнә —
Һаман җавапсыз калам.

* * *

Мин сирень түгел, яз саен
Шау чәчәкле булалмыйм.
Чәчәк атар өчен генә
Сирень булып туалмыйм.

Мин кеше, сиреньле дөнья
Җыр булып иңгән җанга.
Язам! Матурлык калдырыйм,
Тугры калыйм иманга!

* * *

Хиснең ялганы да кайнар —
Җаныңны өтеп ала.
Ашыгып җәймә колачың,
Алдана күрмә, бала!
Хисләрнең өч көнлегенә
Гомерлек диеп бакма.
Хис диңгез ул, сак була күр,
Чүпкә әйләнеп акма!
Хисләр татлы телле була,
Син тыңла акылыңны.
Боз булып, юк, яшәп булмый,
Сүндермә ялкыныңны.
Ялгышма гына, ялгышма,
Тормышта ни ямь кала,
Үкенеп әрнегән чакта
Чәчәк кебек кыз бала?!

* * *

Һәрчак әйтәм: «Бирешмимен,
Мин әле, — дим, — көчемдә!»
Кулларымны күтәрәлмим
Чәчем тарар өчен дә...
Җиргә басып йөргәнемне
Төшемдә күрәм бары.
Юк, беркемгә ишетелмәс
Күңелем аһы-зары!

Суларында йөзә алмыйм,
Менә алмыйм тавына.
Ләкин барыбер тормышның
Ямьнәренә табынам.
Бер көнемне яшәр өчен
Кеше ярдәме кирәк...
Дару эчәм, — тибүеннән
Туктамасын тик йөрәк!

## *Өмет*

Сөюгә хыянәт итсәләр,
Чәчәкле болыннар карая.
Хыянәт итсәләр дуслыкка,
Яктылык үтәр юл тарая!
Туган җир, туган тел өчен дә
Хыянәт җәзасын алалар.
Хыянәт иткәннәр белсеннәр:
Җырсыз да, моңсыз да калалар.
...Җәзасыз булырлар, дим, бәлки
Бишектә тирбәлгән балалар!

## *Күрерсез!*

Мактап күккә күтәрмәгез,
Үзем күтәрелермен.
Кылган матур эшләремне,
Нур сибәргә, кояш итеп,
Зәңгәр күккә эләрмен!
Хурлап җиргә таптамагыз,
Барыбер үкенерсез.
Мин чүп булып җирдә ятмам,
Шау чәчәкле бер гөл булып
Үсүемне күрерсез!

## *Җырлар иде*

Әгәр кеше белсә ниләр
Күрәчәген,
Һәм ул белсә кайчан, ничек
Үләчәген,
Яши алыр иде микән
Шулай көлеп? —
Аның көлүеннән тора
Нур бөркелеп!
...Җырлар иде микән соң ул?
Җырлар иде!
Йөрәк-былбыл җырсыз ничек
Чыдар иде?!
Әйтсәләр дә: «Син бит бүген
Үләсең!» — дип,
Соңгы тибешеңне, йөрәк,
Җыр белән тип!

* * *

Сугышалар нәкъ каршыма
Төшеп ике күгәрчен.
Тәрәзә башы өченме,
Әллә зәңгәр күк өчен?!
Канады очар канатлар,
Сугыш һаман тукталмый.
Кычкырам шушы халәткә
Түзәр хәлләрем калмый:
Нигә кирәк канлы сугыш,
Әллә шушы дөнья тар?
Сездән башка җан тетрәгән,
Җир өстендә, җирләнмәгән,
Сугыш корбаннары бар!

* * *

Сандугачлы авылдан мин,
Шуңадыр җыр яратам.
Күкрәк тулы хисләремне
Бер моң итеп таратам.

Яңа җырлар отарсың, дип,
Кырларга дәшә тургай.
Сандугач бугай мин үзем,
Мин үзем тургай бугай!

* * *

Кояш нурын имә сабый яфрак,
Яңа язның сихри иртәсе!
Хыялларым дәшә зәңгәр күккә,
Юк, җиремнән килми китәсем,
Яшел җирдән килми китәсем!

Алдамасын әле ялган хыял,
Күктә түгел минем урыным.
Бар гүзәллек җирдә минем өчен,
Мин чәчәкләр белән булырмын.
Чәчәк булып җирдә яшәрмен дә,
Чәчәк булып җирдә сулырмын!

Кояш нурын имә сабый яфрак,
Бишек иткән йомшак таң җилен.
Шушы матурлыктан мәхрүм итмә,
Яшеллегең җуйма, әй, Җирем!

* * *

Хыяллар гел әйдәп торалар
Ай-Кояш, йолдызлар иленә.
Ә кеше, барыбер гашыйк ул,
Чәчәкләр тирбәлгән җиренә!
Гашыйк ул һәр кыяк-үләнгә,
Гашыйк ул давылы-җиленә.
Мең тапкыр булса да күкләрдә,
Ул белә: барыбер ятачак
Мәңгелек түшәге — җиренә!

## *Кошлар аңлар*

Авылымның саф һавасын
Рәхәтләнеп сулыйм.
Бәхетлеләрнең дә иң-иң
Бәхетлесе булыйм!

Урамнардан үтим әле,
Сагынуымны басыйм.
Авылдашларымны тизрәк
Күрергә дип ярсыйм.

Мин чыгармын иген үскән
Иркен кырларыма.
Тургай зәңгәр күге белән
Керсен җырларыма.

Көтү йөргән болыннарны
Төшләремдә күрдем.
Туган җирем чәчәкләрен
Чәчләремә үрдем.

Уяндым да үксеп куйдым,
Сүгеп язмышымны.
Ишеткәндер шулчак авыл
Йөрәк тавышымны.

Яшел яфракларын ярып,
Көткән мине таллар.
Кайтып тирәкләргә кунган
Кошлар гына, бары кошлар
Минем хәлне аңлар!

## *Яшәрү*

Беренче күкрәү, беренче
Яшенле яңгыр ява.
Күңелгә шатлык, күкрәккә
Тула шифалы һава!

Яшәрә таллар-тирәкләр,
Яшәрә җирнең өсте.
Әллә яшел яңгыр ява,
Әллә яшел җил исте?

Юк ла, берни гаҗәп түгел,
Яшьлек яшьнәве җанда!
Яшәрми кара, ямь-яшел
Май ае елмайганда!

## *Яз килгәндә*

Усал язмыш кул-аякны богаулады,
Уйлагандыр утырыр, дип, үксеп-елап.
Мин язларны каршы алам, яна-яна,
Сөю турындагы яңа җырым җырлап.

Мин күрәшәм иреннәрне тешли-тешли,
Яшәү турындагы уйлар — чиксез алар!
Нигә әле бөгелергә-сыгылырга,
Бөреләрен ачкан чакта нечкә таллар?!
Рәхмәт сиңа, авыр язмыш, явыз язмыш,
Рәхмәт, җаным мәхәббәттән мәхрүм түгел!
Сулык-сулык сызласа да тәнем бүген,
Умырзая булып көлә минем күңел!

## *Ат чабышы*

Атлар килә, атлар чабып килә,
Кем беренче булыр, кем узар?
Иң беренче килеп сабантуйга,
Сәлам биреп кулын кем сузар?

Ишетелә тояк тавышлары,
Менә-менә килеп җитәләр.
Атлар чабып килә, юлларына
Куелмасын берүк киртәләр!

Йөрәкләре ярсый бабайларның,
Атлар чабып килгән чакларда.
Аларның бит егет чагы булып,
Оныклары җилә атларда.

Шау-гөр килә болын, сөлгеләрнең
Җилфердәве шундый күңелле.
Сабантуйлар белән гармун тартып,
Бәйрәм генә түгел, һәммәбезгә
Яңа яшьлек килә түгелме?!

* * *

Мәхәббәт, син кошлар булып,
Күктә канат кагасың.
Ук аталар, яраң каный,
Канасын ла, канасын!

Синдә көч бар, мең яралан —
Барыбер тереләсең.
Шаулы язның гөле булып,
Яктыга үреләсең.

И мәхәббәт, йотылсаң да,
Сагыш ачысы булып,
Син талларда тирбәләсең,
Ләйсән тамчысы булып!

## *Яз яме*

Оясына кайтты сыерчык,
Шатлыгының юктыр чикләре.
Ишетәм бит күрше әбидән:
«И, аллага шөкер, кайттым! — ди, —
Үзләренә булсын читләре!»

Кыш чыгарга диеп шәһәргә
Алып китә аны уллары.
Ярый әле, ярый, бар икән
Бу тормышның шулай кирегә
Алып кайта торган юллары.
Оясына кайтты сыерчык!

* * *

Тәрәзә башында чи-чи
Килә сабый күгәрчен.
Әле аның елый гына
Белгән чагы, күрәсең!

Канатларын ныгыткач та,
Талпыныр биеклеккә.
Парын табар, күтәрелгәч,
Кояшлы зәңгәр күккә.

Гөрли-гөрли яшәр алар,
Корырлар яңа оя.
Яңа оялар корырга,
Бишек-бәллүләр эләргә
Яратылган бу дөнья!

* * *

Авыр сүзләр ишеткәндә,
Бар үксеп яшь түккән чагым.
Ачу саклап яшәмимен,
Тапланмасын күңел агым!

Үпкәләмим, сәлам бирәм,
И кызарып китә йөзе!
Кабат телен чәйни-чәйни,
Үкенәчәк бит ул үзе,
Гомер буе җанын өтәр
Газабына әйләнәчәк
Миңа әйткән шул бер сүзе!

## *Рәхмәт догасы*

Рәхмәт, әнкәй, күкрәк сөтең өчен,
Бишек җырың өчен рәхмәт сиңа.
Рәхмәтем зур, тормыш давылына
Бирешмәскә син көч бирдең миңа.

Әйттең миңа соңгы сүзең итеп:
«Көләрсең дә әле, еларсың да,
Җил-яңгырлар тияр, шулчакларда
Көчең җуйма бер үк, миннән соң да!»

Рәхмәт, әнкәй, соңгы сүзең өчен,
Рәхмәт сиңа төшкә керүеңә,
Өндә кебек инде төшләремдә
Чәчләремә гөлләр үрүеңә!

Оҗмах сиңа ачсын ишекләрен,
Кәүсәр-чишмә аксын синең алда.
Рәхәтләре булып мәңгелекнең,
Минем рәхмәтләрем барсын анда!

## *Тиң яр*

Бармагымда туй балдагы,
Ялгыз түгел мин, парлы!
Лачын кошларга тиң итеп,
Сайладым сөйгән ярны!

Утка керә, суга керә
Сине өзелеп сөйгән яр!
Икәү бергә инде ничә
Җил-давылны җиңгән бар!

Агып килгән кара болыт
Кояшны каплый ала.
Ә сөю, тиң парлар барда,
Барыбер балкып кала!

Бармагымда туй балдагы,
Ялгыз түгел мин, парлы!
Ходаемнан сорап алдым
Яшәр көч бирер ярны!

* * *

«Мин хатын-кыз!» — диеп ничә әйтсәм дә,
Кими белмәс ул миндәге гүзәллек.
Сабырлыкны гына әйт син, ул миндә
Әллә күпме кайгыга да түзәрлек.

Мин хатын-кыз, шатлыктан да яшь чыга,
Искән җил дә чиртеп үтә күңелемне.
Бер минутым үтми бушка-заяга,
Эшем белән матур итәм көнемне.

Уем барга моңым бардыр, дәрьядай,
Дулкыннарын ярып үтә күкрәгем.
Гел кояшлы гына көннәр көтәм мин,
Хыял-йолдызларга тулы күкләрем.

Мин хатын-кыз, ялкыннарда мең янып,
Сөярлек һәм сөйдерерлек көчем бар.
Кар-буранда язлар булып елмаям,
Мине чәчәк итеп күргән кешем бар!

## *Көт кенә*

Кояшлы дөньяда син барны
Белмәгән чагында йөрәгем,
Адашып очканмын күкләрдә,
Юлларда адашып йөргәнмен.

Белмимен, ничек ямь тапканмын,
Мин синсез яшәдем микәнни?
Тавышың ишеттем, ул инде
Җанымны иркәли-иркәли.

Карашың — гөнаһсыз яктылык,
Иреннәр ут инде, ут менә!
Мәхәббәт килер яз икән ул,
Өметең сүндерми көт кенә!

## *Көндәш*

Шомырт кебек кара чәчләр,
Күзләре тора көлеп.
Иреннәре — чәчәк таҗы,
Торам үбәсем килеп.

Әйтсәм әйтим: мин гашыйкмын,
Янам утларга кереп.
Үсмер кыздай гашыйк булдым,
Синең япь-яшь чагыңдагы
Фотосурәтең күреп!

* * *

Мәхәббәтем — дәрья-диңгез,
Син — аның акчарлагы.
Дулкыннарның ярга кагып,
Тәмам ярсыган чагы.

Акчарлагын күрми торса,
Диңгез җуя тынлыгын.
Кайт, югалта күрмик берүк
Тормышның матурлыгын.

Юк ла, җил-давыл алалмас
Диңгезнең зәңгәр төсен.
Саубуллаштык. Бәләм — киттең
Сагынып кайтырга, мин калдым
Сагынып көтәр өчен!

* * *

Күрешергә насыйп булсын,
Я, исән бул, хуш инде.
Син әле китәсең генә,
Мин сагындым шул инде.

Китми калып булсын иде
Юллар чакырганда да.
Азга гына ялгыз калам
Таллар яфрак ярганда.

Ялгызларга сабырлыклар,
Түземлекләр бирсен берүк,
Кошлар оя корганда!

* * *

Кояшка карап үсә гөл,
Кояшка карап көлә.
Минем дә җиргә ямь бирер
Бер гөл буласым килә.

Кояшым, дип синә бактым,
Карашыңда җылы бар.
Язларның бар сандугачы,
Йөрәгемнең җыры бар!

Күзләреңдә нур-яктылык,
Ялкыннар булып янам!
Кояшка карап көлә гөл,
Мин яктыга ышанам!



# Җырлар

## *Минем гөлләрем*

*Наил Шәймарданов көе*

Күз яшьләре белән үксетерлек,
Кайгы алып килсә көннәрем,
Гөлләремә карап юанамын,
Шау чәчәкле минем гөлләрем.
Ак чәчәкле минем гөлләрем!

Җаннарымны өтеп утлар белән,
Сагындырса әллә кемнәрем,
Гөлләремә карап юанамын,
Чәчәк кенә минем гөлләрем.
Ал чәчәкле минем гөлләрем!

Йөрәгемә сыймас шатлыкларын
Алып килгән чакта көннәрем,
Әнкәм кебек елый сөенеченнән
Кызыл чәчәк аткан гөлләрем.
Гөлләрем бар, минем гөлләрем!

## *Бөгелмәгез*

Салкын җилләр искән чакта,
Елаган гөлләр була.
Елаган гөлләрне күргәч,
Күзләргә яшьләр тула.

Кушымта:

*Җыр белән дәшәм гөлләргә:*
*Җилләргә бөгелмәгез.*
*Авырлыкларга түзегез,*
*Бөгелмәгез, үлмәгез!*

Бозлы карлар яуганда да,
Балкып көлгән гөлләр бар.
Әллә нинди чаклар була,
Әллә нинди көннәр бар!

Кушымта:

*Җыр белән әйтәсем килә:*
*Җилләргә бөгелмәгез!*
*Елаган гөлләр булмагыз,*
*Берүк, сына күрмәгез!*

## *Төшләремдә күрәм*

*Наил Шәймарданов көе*

Төшләремдә күрәм авылымның
Каеннарын, тупыл, талларын.
Төштә күрәм ап-ак бураннарын,
Кош сайраган җәйге таңнарын.

Төштә күрәм сине, авылдашым,
Кара кайгы килер булса да,
Төшләремә килеп керәсең син,
Йорт-иленә шатлык тулса да.

Тәрәзәмне җилләр кага, димә,
Бәлки әле җилләр түгелдер.
Тәрәзәләрне җилләр булып каккан
Сагыну белән тулы күңелемдер!

## *Туган як*

*Рамил Гыймранов көе*

Кочагыңда күреп туймас
Чәчәкләр үсә икән,
Җырың кебек, җилләрең дә
Юатып исә икән.

Кушымта:

*Гүзәлләрдән, әй, гүзәл як,*
*Туган як!*

Кояш нурын дулкын итеп,
Ак болыт йөзә икән.
Синнән ерак яшәүләре
Үзәкне өзә икән.

Кушымта.

Чишмәләрнең агышы да,
Тәме дә бүтән икән.
Әй, белмәдем, чәчәк кебек,
Гомеркәй үткән икән.

Кушымта.

## *Әни күзләре*

*Фирзәр Мортазин көе*

Иң йомшак куллар,
Иң көчле иңнәр
Тик әниләрдә,
Юк аңа тиңнәр.

Әниләр күзе —
Иң матур күзләр.
Әниләр сүзе —
Иң назлы сүзләр.

Алар бирәләр
Иң дөрес киңәш.
Алар булалар
Иң яхшы сердәш.

Иң нечкә күңел,
Иң саф, зур йөрәк,
Иң кайнар сөю,
Иң изге теләк.

Иң җылы куен —
Тик әниләрдә.
Бәхет бар алар
Булган өйләрдә.

Яшәү ямен сез
Биргән бит безгә,
Әниләр, рәхмәт,
Мең рәхмәт сезгә!

## *Каберенә килдем*

Каберенә тагын килдем, әнкәй,
Гөлләренә сулар сибәргә,
Син яраткан кызыл чәчәкләргә
Кайгы-шатлыкларым сөйләргә.

Кабереңдә матур гөлләр үсә,
Синең җаның, әнкәй, аларда.
Мине юатырга, гөлләр булып,
Төреләсең яңа язларда.

Каберенә тагын килдем, әнкәй,
Күңелемнән сагыш түгелә.
Җилләр булып сөрт күз яшьләремне,
Үксүләрем юкка түгел лә!

## *Авылыма кайтам*

*Карам Әплиуллин көе*

Алтын яфрак сипкән көзләр булып,
Ап-ак карлар яуган кыш булып,
Умырзая үскән язлар булып,
Тирәкләргә кунар кош булып,
Авылыма кайтам,
Авылыма кайтам,
Авылыма кайтам.

Сызылып кына аткан таңнар булып,
Балкып торган яңа көн булып,
Ялкынланып янар кичләр булып,
Мең йолдызлы шигъри төн булып,
Авылыма кайтам,
Авылыма кайтам,
Авылыма кайтам.

Сердәш булып бөдрә каеннарга,
Моңдаш булып аккан суларга,
Иркәләнеп назлы җилләренә,
Саф һавасын иркен суларга
Авылыма кайтам,
Авылыма кайтам,
Авылыма кайтам.

## *Яфрак сибә ак каен*

*Зиннур Мөхәммәтдинов көе*

Әйләнә дә килә көзләр,
Яфрак сибә тирәкләр.
Тик көзләрне, моңсу көзне,
Кабул итми йөрәкләр.

Йөрәкләргә көзләр килми,
Тоймый җан көз салкынын.
Йөрәкләрдә язгы ярсу,
Анда язлар ялкыны!

Әйләнә дә килә көзләр,
Яфрак сибә ак каен.
Елларымны санама син,
Яшел генә чаккаем!
Яшел генә чаккаем!

## *Төшләремә керерсез*

*Фәнир Галимов көе*

Ник моңланам икән дисәм,
Китәр көнем җиткән лә.
Бер өзелмим, мең өзеләм,
Авылымнан киткәндә.

Кушымта:

*Төшләремә сез керерсез,*
*Кырларым, тугайларым.*
*Сез минем сагыну дулкыным,*
*Әйләнеп кайтыр ярым.*

Кемнәр уйлап тапкан икән,
Аерылып китүне.
Аерылып, йөрәкләрне
Ут-газаплы итүне?

Кушымта:

*Төшләремә сез керерсез,*
*Дусларым, туганнарым.*
*Сез минем сагыну дулкыным,*
*Әйләнеп кайтыр ярым.*

Саубуллашу минутлары
Елатмаган кемнәрне.
Китәр юлларыма чыктым,
Көтеп кайтыр көннәрне.

Кушымта:

*Төшләремә сез керерсез,*
*Талларым, матурларым.*
*Сез минем сагыну дулкыным,*
*Әйләнеп кайтыр ярым.*

## *Нигә?*

*Карам Әһлиуллин көе*

Кайгы-хәсрәт бирер Ходай
Яраткан бәндәсенә!

*Хәдистән*

Изге китап, ни сөйлисең,
Юатмакчы булыпмы?
Яратса Ходай, таратсын
Кояшымны каплап торган,
Кояшымны каплап торган,
Түбәмдәге болытны!

Әрнү-сызлануларымнан
Коткарсын җан-тәнемне.
Нигә әле, нигә һаман
Мең сынавы аша күрәм,
Мең сынавы аша күрәм
Киләчәк көннәремне?

Ходай мине яратканга
Ничек ышанмак кирәк?
«Ярату алай булмый», — дип,
Өзгәләнеп-телгәләнеп,
Өзгәләнеп-телгәләнеп,
Кан-яшен түгә йөрәк.

## *Ятимнәр*

*Җәүдәт Хәкимов көе*

Язмышларын каргый-каргый,
Үксеп елый ятимнәр.
Җаннарына җылы биреп,
Юата алыр кемнәр?

Кушымта:

*Балам, дигән сүзне көтеп,*
*Күзгә карый ятимнәр.*
*И сабыйлар, кояш күрми*
*Тилмергән гөлгә тиңнәр.*

Мәхәббәтнең бик тә ачы
Җимеше бу ятимнәр.
Ятимлекнең юлларына
Киртәләр куяр кемнәр?

Кушымта.

## *Аккош*

*Сәүбән Чуганаев көе*

Күк йөзендә кар болыты,
Көз каршылый ак кышны.
Йөрәк әрни кызганудан
Ялгыз калган аккошны.

Кушымта:

*Кышлар суык икәнен дә*
*Белми түгел, беләдер.*
*Тик ул китми, җәйне көтә,*
*Белә аккош — җан дускае,*
*Ак төнбоек булып үсеп,*
*Дулкыннарда тирбәлер.*

Кошлар китте, аккош китми,
Калды йөзгән күлендә.
Ничек китсен, җан дускае —
Тирән күлнең төбендә.

Кушымта.

Күк йөзендә кар болыты,
Көз каршылый ак кышны.
Әй, килер кыш, җырым дәшә:
Туңдырмачы аккошны!

## *Китәбез шул*

Оялары кала, кошлар китә,
Кешеләрдә — кошлар язмышы.
Туган җирләр кала, китәбез шул,
Күргәнегез бардыр, киткәннәрнең
Күзендәге яшьне, сагышны.

Оялары кала, кошлар китә,
Язга кадәр генә китәләр.
Туган авыл кала, китәбез шул,
Эчәр сулар читтә булгангадыр,
Китәр юлда булмый киртәләр.

Ояллары кала, кошлар китә,
Кешедә дә — кошлар язмышы.
Туган җирләр кала, язмыш, диләр,
Язмыш үзе микән, киткәннәрнең
Түгел микән бары ялгышы?

## *Игенче җыры*

*Җәүдәт Хәкимов көе*

Мин кырларда иген үстерәм,
Байлык бирәм туган илемә.
Тамган тирем, тырыш хезмәтем —
Кайнар сөю туган җиремә.

Мин кырларда иген үстерәм,
Бәхет бирәм газиз халкыма.
Уңышларым артса ел саен,
Очар коштай булып талпынам.

Мин кырларда иген үстерәм,
Иминлеген теләп дөньяның.
Яу яланы түгел, иген кыры
Иңләп алсын бөтен Җир шарын!

## *Ак каеннар*

*Гөлнара Зиязова көе*

Җәй буена каеннарга
Серләремне сөйләдем.
Талгын җилгә кушылдым да
Сагынуымны көйләдем.

Кушымта:

*Каеннарны сагышсыз, дип,*
*Уйлап ялгышканмын ла.*
*Язмышлары тиң икән бит*
*Кеше язмышларына.*

Ак каеннар тын тордылар,
Сабыр иткәннәр икән.
Үз хәлләрен сөйләр өчен,
Күзне көткәннәр икән.

Кушымта.

## *Кыңгыраулы дугалар*

*Карам Әһлиуллин көе*

Парлап җиккән туй атлары
Узып бара урамнан.
Кыңгыраулы дугаларга
Ефәк яллар уралган.

Кушымта:

*И чаба атлар, бәхеткә*
*Илтер юлдан чабамы?*
*Атлар чаба, энже карлар*
*Төреп алган чананы.*

Иңнәрендә ап-ак шәле,
Күлмәккәе кардай ак.
Җиткән вакыт, ак чәчәк, дип,
Түшкә кадар гына чак.

Кушымта.

Тыным өреп эретәм дә
Тәрәзәмнең бозларын,
Моңга тулып карап калам
Авылымның кызларын.

Кушымта.

Их, күңелле кыш көнендә
Ямьле туйлар булуы!
Шатлыктан, бары шатлыктан
Күзләргә яшь тулуы!

Кушымта.

## *Ак чишмә килен каршылый*

*Инсаф Хәбибуллин көе*

Суым тәмле, үкенмәссең,
Чиләкләрең тутырып ал.
Эчәр суың миндә булсын —
Гомерлеккә бездә кал.

Кушымта:

*Тормышыңа бәхет юрап,*
*Ак күлмәгең кигәнсең.*
*Бер күрмәгән чит җирләргә*
*Килен булып килгәнсең.*

Үз итәрсең, тәм табарсың,
Ямь табарсың җиремдә.
Әле бездән аерылып
Китмәде бер килен дә.

Кушымта.

Көянтәңә нурлар кунган,
Иңбашыңа алып сал.
Ак суларым — ак теләгем,
Үз өлешең алып кал.

Кушымта.

## *Кыз бала язмышы*

Матурлык иркәли күзләрне,
Талларны ап-ак бәс сарыган.
Күңелдә җыр булып тибрәлгән
Авылым кышларын сагынам.
Авылны сагынам, сагынам.
Талларны ап-ак бәс сарыган!

«Ни булды сиңа?» — дип сорама
Сагышлы чагында күзләрем.
Авылның язларын сагынам,
Сагынам җәйләрен, көзләрен.
Юату сүзләре эзләмә,
Сагышлы чагында күзләрем.

Китмичә ни хәлләр итәсең,
Кыз бала язмышы шул икән!
Сөйгәнең яшәгән авылның
Талына кош булып кун икән!
Бәхетле булсам да сагынам,
Кыз бала язмышы шул икән!

## *Яшьлек дустыма*

*Карам Әнлиуллин көе*

Көтмә инде, күңел,
Өзел, өмет, өзел,
Көзге яфраклар кебек.
Көткәнеңне белмәс,
Килмәс инде, килмәс,
Язгы кояштай көлеп.

Очраштырган кичләр,
Ялкын тулы хисләр,
Гүзәл җыр булып калсын.
Җырым моңга тулып,
Сәламнәрем булып,
Яшьлек дустыма барсын!

## *Язлар килер әле*

*Әнвәр Шаһиморатов көе*

Сары яфрак күреп моңсуланма,
Син хәтерлә аның яшел чагын.
Сагынсаң да кабат очрашуга
Өметеңне өзми генә сагын.

Сары яфрак җилдә калтырана,
Син өшемә берүк, син өшемә.
Миндә әле язлар җылысы бар,
Илтәм сиңа — бердәнбер кешемә.

Сары яфрак күреп моңсуланма,
Син хәтерлә аның яшел чагын.
Безне очраштырыр таңнар атар,
Язлар килер әле, килер тагын.

## *Кил син миңа*

*Фәнир Галимов көе*

Кышлар салкын, димә, кил син миңа,
Онытамасаң бергә чакларны.
Җылы тыным белән эретермен
Чәчләреңә кунган ак карны.

Кышлар салкын, димә, кил син миңа,
Сагынганда ерак язларны.
Карлар гына күмеп китә алмый
Күңелдәге ямьне, назларны.

Төренеп кил ап-ак бураннарга,
Озата килсен, әйдә, салкыннар.
Йөрәгемдә җилекләргә үтәр
Салкыннарны җиңәр ялкын бар!

## *Күрәзәче*

*Карам Әһлиуллин көе*

Күрәзәче, күрәзәче бит мин, күрәзәче,
Беләм, җиңәр, беләм, җиңәр сагынулар көче.
Мин күтәрмен, мин күтәрмен
ялкыннарда янып,
Син килерсең, син килерсең кар-бураннар
ярып.

Күрәзәче, күрәзәче бит мин, күрәзәче,
Кулларыңны, кулларыңны кулларыма бирче.
Мин бит синең, мин бит синең тулган айлы
төнең,
Ә син минем, ә син минем ямьле аяз көнем.

Күрәзәче, күрәзәче бит мин, күрәзәче,
Беләм, җиңәр, беләм, җиңәр мәхәббәтнең
көче.
Аерылса да, аерылса да бүген барган юллар,
Көтә безне, көтә безне бергә яшәр еллар!

## *Язмыш шулдыр*

Кар-буранлы юллар үтеп,
Миңа киләсең.
Моңсу карап, кулларыма
Кулың бирәсең.

Кушымта:

*«Мин бит сине бик сагынам!» –*
*Дисең уфтанып.*
*Язмыш шулдыр, ике яры*
*Яшибез янып!*

Язларымның сандугачы
Булып киләсең.
Уйга чумып, башкаеңны
Түбән иясең.

Кушымта.

Юлларыңа коеп ява
Яфрак яңгыры.
Яңгырый һаман күңелнең
Сагышлы җыры.

Кушымта.

## *Бәхетле көнем булып*

*Салават Низаметдинов көе*

Кош булып барырмын сиңа,
Бакчаңда тирәк булса.
Өзлексез сайрап торырмын,
Җаныңа кирәк булса.

Яңгырлар булып явармын,
Яшьнәрмен яшен булып.
Түгелермен күзләреңнән,
Шатлыклы яшең булып.

Калырмын синең гомерлек
Алың да, гөлең булып.
Син бер генә кара минем
Бәхетле көнем булып.

## *Ай яктысы*

Тәрәзәмдә — ай яктысы,
Йокысыз калган чагым.
Күзләремә мөлдерәмә
Яшь булып тулдың тагын.

Кушымта:

*Айлы төн, гашыйклар төне,*
*Нигә без бергә түгел?*
*Әрнепләр әрни яралы,*
*Канаты сынган күңел!*

Тәрәзәмдә — ай яктысы,
Уйларым сиңа илтә.
Айлы төннәр йөрәгемне
Сагышлы ялкын итә.

Кушымта.

Тәрәзәмдә — ай яктысы,
Бирсен Ходай сабырлык.
Икебез дә бер-беребезне
Өзелеп-өзелеп сагындык.

Кушымта:

*Айлы төн, гашыйклар төне,*
*Нигә без бергә түгел?*
*Килер көннәр кавыштырыр,*
*Өметсез түгел күңел!*

## *Кемне кем?..*

Кемне кем эзләп тапты да,
Югалтты соң кемне кем?
Кем бүген ныграк юксына,
Моң-сагышлар кемнеке?

Кемне кем чынлап яратты,
Кем вакытлыча гына?
Кемне кем ташлады шулай
Җил-давыл кочагына?

Йөрәктәге яраларның
Сызлавы, бәлки, үтәр.
Минме сине, синме мине —
Кемне кем гафу итәр?

## *Кояшлы яңгыр*

Күзләрнең дә кояшы бар,
Өшермен кебек түгел.
Шатлыгы-куанычыннан,
Юк, мәхрүм булмас күңел.

Күзләрнең дә гөлләре бар,
Сөйгәнем өзәр әле.
Иркәләп назлы сүзләрен,
Төймәдәй тезәр әле!

Күзләрнең дә яңгыры бар,
Күкләрне каплый болыт.
Көз, дими, сөю елмая,
Кояшлы яңгыр булып!

## *Мин – чәчәк*

*Әнвәр Шаһиморатов көе*

Үрелеп үсәм кояшка,
Тирбәләм назлы җилдә.
Димәк, мин — бер гөле язның,
Димәк, мин — чәчәк җирдә!

Гел аяз булсын күк йөзе,
Каплама, кара болыт.
Көннәребез торсын әле
Кояшлы гына булып.

Тормышның яме китмәсен,
Боз яумасын чәчәккә.
Мин чәчәкләр матурлыгын
Илтәрмен киләчәккә.

## *Җаныма сарылгансың*

*Карам Әhлиуллин көе*

Бөгелдем, сыгылып төштем,
Сагыну мине җиңде.
Сандугачым булып, кайчан
Кайтырсың икән инде?

Бөдрә тирәккәең булып,
Көтәм дә көтәм сине.
Аерма кояшлы күктән,
Канатсыз итмә мине.

Ашык кайтыр юлларыңа,
Үзең дә сагынгансың.
Сагынгансың, бер моң булып,
Җаныма сарылгансың!

## *Китмә*

*Миңнулла Дәүләтбаев көе*

Канатлар да каерылмасын,
Йөрәкләр дә аерылмасын,
Аны ташлап китмә, китмә.
Ул бит синең яшьлек таңың,
Өзелеп сөйгән тәүге ярың,
Боектырма, ялгыз итмә.

Еракларга китеп кенә,
Онытылсын ничек кенә,
Зәңгәр кичләр, уртак хисләр?!

Язгы сулар аккан чакта,
Гөлләр чәчәк аткан чакта,
Йөрәккәе синсез нишләр?

Бергә чаклар нинди ямьле,
Яннарында бул син мәңге,
Сайрар гына кошкаеңның
Үзәккәе өзелмәсен,
Күз яшьләре түгелмәсен
Җандай якын дускаеңның!

## *Сөйгән кешемә*

*Ринат Мәҗитов көе*

Иңнәреңә карлар булып
Явам, өшемә.
Күңелемнең ак энҗеләре —
Сөйгән кешемә.

Бөгелмә син, давыл итсәм,
Бөтен көчемне.
Мәхәббәттә сынавым бу
Сөйгән кешемне.

Карашымны ерак ташлап,
Кыссам тешемне,
Ул — минем көтә белүем
Сөйгән кешемне.

Карлар булып явам бүген,
Тик син өшемә.
Кайнар йөрәк җырым сиңа,
Сөйгән кешемә!

## *Син килдең*

Ерак та булмаган ара,
Юл гына тапмаганбыз.
Өметләрне сүндермичә,
Беркемгә дә сиздермичә,
Бер-беребезгә йөрәкләрнең
Ялкынын саклаганбыз!

Бер-беребезгә тиң яр булып,
Хыялда сөешкәнбез.
Өметләрне сүндермичә,
Беркемгә дә сиздермичә,
Хыялда, бары хыялда:
«Бәхетем син!» — диешкәнбез.

Салават күпере буйлап,
Син бит ул миңа килдең.
Чик куелды сагышыма,
Рәхмәт әйтеп язмышыма,
Сине сөеп каршы алдым,
Назлысы булып җилнең!

## *Бәхет гөлем булып үссәңче*

*Дамир Заһитов көе*

Ак каенның сары яфракларын
Сагынуларым итеп белсәңче.
Җаннарымны күзләр өшеткәндә,
Җылы язлар алып килсәңче.

Ак каенның сары яфракларын,
Күз яшьләрем итеп белсәңче.
Ачылганда каен бөреләре,
Ләйсән яңгыр булып көлсәңче.

Ак каенның сары яфракларын,
Үзең җилләр булып өзсәңче.
Язларымда, килер язларымда,
Бәхет гөлем булып үссәңче!

Рәфис МӨХӘММӘТДИНОВ

# Хисләрем-ташкын





*Миңа быел 47 яшь тулды. Шушы гомерем буенча мине әнкәм кулында күтәреп тәрбияләде, аның тәрбиясендә яшәдем, аякларыма басалмыйм. Үкенечкә каршы, газиз әнкәм быел җәй уртасында якты дөньядан китте, урыны оҗмахта булсын!*

*Әткәм Нәҗип исемле иде, 15 ел элек дөнья куйды. Читтә яшәгән туганнарым кайтып, ярдәм итеп торалар.*

*Мин гүзәл табигатьле Башкортстанның Яңавыл районы Яңа Уртавыл авылында тудым һәм шунда яшим. Тормыштагы матурлыклар да, ямьсезлекләр дә шигырьләрем булып туа. Мәхәббәт турындагы шигырьләрем Кәүсәриямә багышланган, аларның күбесе көйгә салынган. Туган җиремдә яшәвем, яраткан эшем, яраткан кешем булу мине бәхетле итә!*

# Шигырьләр, җырлар

## *Җырлап яшим*

Тибрәлеп ак дулкыннарда,
Шатлык дәрьясында йөзәм.
Җырларымны канат итеп,
Туган илем буйлап гизәм.

Йөрәгемнән чыкты бүген
Җырларымның иң татлысы.
Шигърияттем, сиңа булсын
Хисләремнең иң яктысы.

Җырлап яшәргә язсын, дим,
Халкымның гел батырлыгын,
Тормышның тик матурлыгын.

* * *

Әйткәннәре булды миңа:
«Тормышта хаклык сирәк.
Күзле килеш сукыр булып
Калуың хәерлерәк!»

Ишетмәдем, әллә шуңа
Бик күпләр иш итмәде.
Хәтта дустым табынында
Кайчак урын җитмәде.

Үзем булып калам һаман,
Сөйлимен үз сүземне.
Хаклык күреп яшәр өчен
Ачтым бит мин күземне.

## *Башымны имәм*

Ходай миңа каты сынау биргән,
Хәрәкәтсез аяк-кулларым.
Кеше ярдәменнән тыш кабалмыйм
Авызыма тәгам, суларын.

И Ходаем, күпме каһәрләмә,
Башымны һич түбән имәмен.
Бу дөньяда аяк-куллыларның
Моң-зарларын ишетүе авыр,
Мин: «Бәхетсез булдым», —
димәмен!

## *Егетлек*

Бәрде-какты, типкәләде
Җаннарымны ачы язмыш.
Мескен, диеп әйтмәгез лә,
Күзгә карап берүк ялгыш.

Орынса да тормыш-давыл,
Үтәлмәде тамырыма.
Мин ышанам, азаккача
ЕГЕТ булып калырыма!

* * *

Күәс тутырып камыр изә
Әнкәм ап-ак оннардан.
Һәрвакыттагыча уңа
Икмәк аның куллардан.

Пешергән ашлары була
Телләреңне йотарлык.
Авыр сүзләр әйтмәс һич тә
Йөзләреңне ертырлык.

Яше җитмешкә җитсә дә,
Шөкер, бар әле көче.
Кош-корт, мал-туар асрый,
Буа буарлык эше.

Шомадан гына булган дип,
Әйтәлмим тормыш юлын.
Инде кырык ел күтәреп,
Бага ул чирле улын.

Әнкәм һич тә башын ими,
Горур тота ул үзен.
Җиткәндер инде язарга
Шигырьнең соңгы сүзен.

Чын аналар гына бары
Буладыр шундый түзем.
Әнкәмдә — җир сабырлыгы,
Шул минем әйтер сүзем!

## *Гомер телим*

Тәрәз төпләрендә гөлләр үсә,
Чәчәкләрнең төсе төрлечә.
Үсәр идемени алар шулай,
Әнкәй, синең кулың тимичә!

Көн дә сулар сибеп, тәрбияләп
Үстерәсең саклап, кадерләп.
Кошлар кебек үсеп таралышкан
Нарасыйларыңны хәтерләп.

Туган нигездәге гүзәллекнең
Чикләмәсен Ходай көннәрен.
Озак еллар, тагын озак еллар
Чәчәк атсын, әнкәй, гөлләрең!

## *Туган көнем*

Туганнарым, салкын кыш көнендә
Мондый бүләк кайдан таптыгыз?
Янып торган тере чәчәк тотып,
Бәйрәмемә минем кайттыгыз.

Бүләгегез белән бар күңелем
Дөньяларын әсир иттегез.
Сез бит миңа февраль аенда ук
Җәйләр бүләк итеп киттегез.

Бедсәм дә мин чәчәкнең күп тормый,
Кибеп сулачагын янымда,
Хөрмәтегез шиңмәс чәчәк булып,
Гомерлеккә калыр җанымда.

## *Мин дә бәхетле*

Ак яулыклы әби үтеп бара,
Җилләр җилфердәтә яулыгын.
Карты-яше сәлам биреп уза,
Сорашалар аның саулыгын.

Авылдашлар гына түгел, хәтта
Күрше авыл таный, очратып.
«Кендек әби!» — диеп эндәшәләр
Чын күңелдән аңа, яратып.

Аның ярдәмендә бу дөньяга
Тудырган мине дә әнием.
Язмышларның бәхетлесен теләп,
Кендегемне кискән әбием!

* * *

*Апама*

Җәйләрнең иң җылы, кояшлы,
Чәчәкле аенда тугансың.
Әткәйгә, әнкәйгә һәм безгә
Бер генә кыз бала булгансың.

И гомер дигәнең — аккан су,
Син инде иллегә җиткәнсең.
Шул уңай, зур табын әзерләп,
Энеңнәр килгәнен көткәнсең.

Изгелек кылучы фәрештә,
Булдың син гомергә зур терәк.
Ишетче, йөрәкләр тибәләр,
Безгә бит, апам, син гел кирәк!

Гаиләңә күз генә тимәсен,
Гел шулай шатланып яшәгез.
Балалар кайгысын күрмичә,
Эшләрең уң булып, авырмый,
Бәхетле яшә, дип дәшәбез!

## *Син юк, әткәй!*

Чәчәк атты язын бакчабызда,
Әткәм, син утырткан алмагач.
Авыр икән, бигрәк авыр икән,
Ир балага әткәй булмагач!

Синең киңәшләрең, ярдәмнәрең,
Синең ныклы куллар бик кирәк.
Булыр идең авыр язмышыма,
Исән булсаң, бүген бер терәк.

Коляскамда бакчабызга чыгам,
Чәчәк искәйләрен суларга.
Кереп кенә югалгандай булдың,
Их, әткәем, тирән суларга.

Бирешмимен, әткәй, өйрәнелде
Барчасына инде түзәргә.
Әл дә әнкәем бар яннарымда
Пешкән алмаларны өзәргә!

* * *

Җиргә кадәр бөгеп агачларны,
Җил-давыллар сыный ныклыгын,
Килдем, әткәм, тагын кабереңә,
Бигрәк сагындыра юклыгың.

Кулда чәчәк, шуны кабереңә
Көчем җитми үрелеп салырга,
Анда рәхәт икән дисәләр дә,
Юк, ашыкмыйм әле барырга.

Зарланырга дип килмәдем, әткәй,
Елакларны сөймим, беләсең.
Килә минем иманнәрдәй яшәп,
Үлгәндә дә көлеп үләсем!

## *Мин исән*

Кыш аеның башы бүген,
Декабрьнең нәкъ бере.
Кырыгынчы кышка кердем,
Гомер үтә, мин — тере!

Бар бит: «Ул бичара әл дә
Исәнмени?» — диюче.
Минем өчен әнә шулай
«Борчылучы, көюче».

Ходайга шөкер, бирешмим,
Авыр булса да язмыш.
Исәп әле йөзгә җиту,
Уйлыйсыз үтә ялгыш!

## *Төшләремә керәсең*

Төшләремә бик еш керәсең син,
Сагынуымнандыр, күрәсең!
Бүген тагын күрдем, талчыбыктан
Казларга дип оя үрәсең.

Җитез кулларыңа күз иярми,
Кем әйтәлер уң кул зәгыйфь, дип.
Фашист ядрәсенең кыйпылчыгын
Үзең белән алып киттең бит.

Исән чагында ук үзеңә дә:
«Алтын куллысың син», — диделәр.
Син төзегән йортта гомер итеп,
Баскан пималарны киделәр.

Төшләремә еш керәсең, әткәй,
Әткәй дип, их, өндә дәшергә!
Язсын инде берүк синең кебек,
Дөньялыкта гел изгелек кылып,
Соңгы сулышкача яшәргә!

* * *

Хәтерлим мин күзгә карап,
Әткәм, әйткән сүзеңне:
«Азаккача КЕШЕ итеп,
Калдыр улым үзеңне!»

Гөрләвекләр юып үтә,
Әткәм, соңгы эзеңне.
Мин ышанам, юа алмас
Синең әйткән сүзеңне.
Якты күккә бөркет итеп
Күтәрермен үземне!

* * *

Башындагы шау чәчәкле
Яулыгын артка бәйләп,
Гөлләренә сулар сибә
Әнкәем җырлар көйләп.

Суларын сакчыл йөретә,
Куймыйм, ди, читкә түгеп.
Яшьлегендә откан җырлар
Сагышлы, үзе кебек.

Моңая әнкәй яшьлеге
Җырларын кат-кат җырлап.
Кайтасы киләдер яшьлек
Таңнарын кабат урап.

Сагынадыр әткәй белән
Яшәгән чагын парлап.
Сагыш тулы йөрәккәен
Әнкәем баса җырлап!

## *Сабыр безнең әниләр*

Йомшак куллар, җылы сүзләр
Иркәлиләр, назлыйлар.
Безнең авыр язмышларны
Тик әнкәйләр аңлыйлар.

Безнең өчен тик әнкәйләр
Янып, көеп яшиләр.
Авырлыклар була һәрчак,
Түзә алар, дәшмиләр.

Кичерәләр һәрвакытта
Без ясаган ялгышны.
Яшәсеннәр әле алар,
Җиңеләйтеп язмышны.

* * *

Февраль ае салкыннарга,
Бураннарга бай була.
Быелгы февраль аенда
Миңа кырык яшь тула.

Гомеремнең кышы түгел,
Кояшлы җәе әле.
Күңел бакчамдагы гөлнең
Шау чәчәк аткан мәле.

Язмыш кышның бураныннан,
Салкыныннан аяусыз.
Яшәүләре җиңел түгел,
Гомергә кул-аяксыз.

Ә шулай да елап түгел,
Җырлап яшәгән көнем.
Бәхетле итеп бүген дә
Туды бер шигырь гөлем.

## *Әни*

Әниемнең чәчләренә карыйм,
Сирәк кенә калган карасы.
Маңгаенда тирән бразналар —
Күргәннәрнең ачы ярасы.

Сугыш елларында үсмер кызый,
Җирен сөргән, йөргән тырмага.
Җир үлчәгән, утау утаган ул,
Печән ташыган кыш фермага.

Ачлыгын да, ялангачлыгын да,
Кайгысын да күргән гомерендә.
Яу кырыннан кайткан әти белән
Гаилә корган туган җирендә.

Саф мәхәббәт җимешләре булып,
Дөньяга биш бала килгәнбез.
Килгәнбез дә, шатлык кына түгел,
Кайгылар да өеп биргәнбез.

Сабый чакта беребез вафат булса,
Ә мин авырыйм бала чагымнан.
Сабый тәрбиясе биреп карый,
Юк авыр сүз әни ягыннан.

Безне ташлап мәңгелеккә китте
Әтием дә якты дөньядан.
Сабыр булды, бирешмәде әни,
Нур китмәде туган оядан.

Йөзләренә ап-ак чәчкәйләре
Биргән кебек үзгә матурлык.
Әниемнең шушы яшәү юлы —
Асылда бит олы батырлык!

## *Китмә, әнкәй!*

Шешенгән күз кабакларың,
Авырыйсыңмы әллә, әнкәм?
Синнән калса соң, я, нишләр
Канат астындагы бәбкәң?

Болай да бит ачы язмыш
Аз тундырмый җаннарымны.
Син булганга гына җырлап
Каршылыймын таңнарымны.

Авырмас сөякләр булмый,
Авырсаң да терел, китмә.
Әнкәм, мине канатланып
Яшәвемнән мәхрүм итмә!

* * *

Коляскама килеп тотынды да:
«Мескен», — диде исерек бер бәндә.
Күз яшьләрен сөртә-сөртә әйтте:
«Күрми яшисең бит бер ямь дә».

Җирәндергеч йөзен күрмәс өчен,
Карашымны бордым читкәрәк.
Хәтерем калып аның кылыгына,
Ачу белән әйттем: «Ни кирәк?»

Көчкә-көчкә аягына басып,
Яктан-якка китте сугылып,
Ерак бармалмады, юл читенә
Пычрак ләмгә төште егылып.

«И бичара! — дидем көлемсерәп, —
Син мескен дә түгел, — аяклы.
Син исерек, миндә аек акыл,
Кем мескен соң монда, кем хаклы?!»

## *Нишләр иде?*

«Дөньядан туйдым», — ди берәү,
Аек та болай үзе.
Аяк-куллары да йөри,
Исән-сау ике күзе.

Нишләр иде зәгыйфьләнеп,
Бәндәгә бәндә калса?
Безнең кебек мәңгелеккә
Ходай урынга салса?

Җан-тәннәребез сызлауга,
Учлап дару кабабыз.
Үләсе килгән чакта да
Елмаер көч табабыз!

* * *

Тирәгеннән бер сандугач
Җиргә төште егылып.
Харап булган нинди дошман
Юлларына юлыгып?

Хәлкәйләре авыр икән,
Сынган очар канаты.
Шушы язмышташны күрү
Йөрәгемне канатты.

Учларыма алып кошны,
Хәлен сорыйм, юатам:
«Җырланасы җырларыбыз,
Бик күп әле, җырланыр ул!» —
Дип, яшәр көч уятам.

## *Бәхетем*

Алларымда йошмак мамык сымак,
Җиргенәем, җәйрәп ятасың.
Өсләреңдә яланаяк йөгереп,
Килә минем тәкмәч атасым.

Кырларыңа чәчеп үстерәлмим
Бодай, арпа, борчак, арышын.
Бу бәхеттән мине мәхрүм иткән
Каһәр төшкән ачы язмышым.

Кушучыма алып туфраккаем,
Исни алмыйм татлы исеңне.
Бәхетем шунда, җирем, җырларымда
Кабатлыймын синең исемеңне!

## *Беләсезме?*

Әй, малайлар, исегезгә
Төшәме туган яклар?
Яз кошларга оя куеп,
Гөрләвек куган чаклар?

Исегезгә төшә микән
Шау чәчәкле болыннар?
Шул болында бергә үскән
Шаян җитез колыннар?

Шул колыннар булды безнең
Атланып чапкан атлар.
Исләремнән чыкмый һаман,
Сагындыра шул чаклар.
Беләсезме, шул чакларны
Саклый бит туган яклар!

## *Авылдашым китте*

Күкрәк киереп бер егеткәй
Әйтте, басып каршымда:
«Мин авылдан китәм, — диде, —
Ташлап бүген барсын да.

Эшләсәм, ким-хур булмамын,
Мин ялкау егет түгел.
Бәләкәйдән зур шәһәргә
Тартылып тора күңел».

Авылдашым киткәч тойдым
Гаепледәй үземне.
Ник әйтмәдем йөрәгемнән
Чыккан шушы сүземне:

«Яшьлегеңдә туган яктан
Китүләре җиңел дә.
Туган җирнең туфрагы да
Алтын-көмешләрдән кыйммәт,
Көчең беткәч иңеңдә!»

* * *

Әйдәләмәгез лә инде,
Килми минем китәсем.
Килми туган җирләремнән
Җанны мәхрүм итәсем.

Килми минем кабатлыйсым
Байтакларның хатасын:
Дөньялыктан аерылгач,
Чит җирләрнең туфракларын
Түшәк итеп ятасым.

## *Бабайлар җыры*

Агач ботагында кош оясы,
Оя түбәсендә сыерчык.
Язгы кичләр, таша кайнар хисләр,
Гүя йөздә юк бер җыерчык.

Кошлар сыман очам, канатланам,
Үзем әллә үзем түгелмен.
Язлар белән яшьлегемә кайттым,
Унсигездә бүген күңелем.

## *Кайт, авылдаш!*

Калалардан ким-хур түгел авылым,
Аның урамнары таш кына.
Тирә-юньдә зур-зур йортлар калка,
Күңел яшәргә гел ашкына.

Торбалардан килә чишмә суы,
Сый-нигъмәттән өстәл сыгыла.
Мичләргә дә инде утын түгел,
Зәңгәр ягулыклар ягыла.

Һавасы соң аның, саф һавасы,
Йөрәккә май булып ягыла.
Бу шатлыкка янә бер ямь өстәп,
Кайт, авылдаш, туган ягыңа!

* * *

Гармун уйный бер ир-егет,
Бармагында алтын балдак.
Үзәк өзгеч моң агыла
Тирә-юньгә шундый салмак.

Кайгысын да, шатлыгын да,
Сагышын да түгә генә.
Авылдашым кайткан сагынып
Егет булып ныгып җиткән,
Беренче кат гашыйк торткан
Туып-үскән төбәгенә.

* * *

«Миллионнар алып эшлимен,
Авыл миңа нәрсәгә.
Шәһәремдә гулять итәм,
Куллар тыгып кесәмә.

Азык-төлек бәясе дә
Арзан бит бездә шактый», —
Кайткан саен авылдашым
Яшәгән җирен мактый.

«Елга бер дә кайтмас идем,
Монда әнием яши».
Киткән чакта авылдашым
Сумкаларын чак күтәрә,
Елмаеп калам, дәшми.

## *Ерактагы дусларга*

Берәү дәшә: «Кил син безгә,
Төзеп бирәм зур пулат.
Җәннәткә тиң булыр эче,
Яшәрсең иркен сулап».

Берәү әйтә: «Кил син, бездә
Сайрый оҗмах кошлары.
Ел әйләнә җимеш ашыйм,
Булмый салкын кышлары».

Туган якның салкыны да
Җаныма бирә рәхәт.
Китәмме соң туган җирдән,
Хөрмәтегезгә рәхмәт.

Беләм бит мин киткәннәрнең
Үкенеп яшәгәнен.
Сагышлардан күзләремнең
Теләмим яшьләнгәнен.

## *Җәйге көндә*

Як-якларымда әйләнеп,
Бер күбәләк уйнап оча.
Чәчләремә килеп куна,
Иңнәремнән килеп коча.

Нишләп мине бу күбәләк,
Ярatty соң, бик үз итте!
Бераз яннарымда булгач,
Зират якка очып китте.

Әйтәләр ич, үлгәннәрнең
Рухлары кайта очып.
Мөгаен, әткәй кайткандыр,
Күрешкәндер кочып-кочып.

* * *

Гомерләр, и газиз гомерләр,
Вакытлы-вакытсыз өзелә.
Авылыбыз зираты эчендә
Өр-яңа каберләр тезелә.

Картаеп дөньядан киткәннәр
Азрактыр, әгәр дә санасаң.
Күп кенә үлемгә эчкелек
Сәбәпче бит, шуны аңласак.

Кешенең гомерен чәчәкләр
Гомере белән гел тиңлибез.
Нигә шул, шул кыска гомернең
Кадерен белмибез, белмибез?!

## *Синдә калам*

Якын миңа, шундый якын,
Атамнан калган нигез.
Алтыпочмаклы йортымның
Бүрәнәләре тигез.

Эче нурлы, һавасы саф,
Рәхәтләнеп тын алам.
Әнкәм әйтте: «Тугач синең
Кендегең дә бит киселде
Шушы нигездә, балам».
Туган нигез, азаккача
Бик бәхетле булыр өчен
Мин синдә торып калам!

## *Иртәнге җыр*

Бакча арты яшел болын,
Ак чәчәккә төренгән.
Талларында кошлар сайрый,
Чылтырап ага чишмәләре,
Бар тереклек терелгән.

Очып уйный күбәләкләр,
Гүзәллеккә — гүзәллек.
Җәйге иртә, мин бит гашыйк,
Сиңа гашыйк, хәлләрем юк
Җырламыйча түзәрлек.

## *Җәйге таң*

Авылыбызның җәйге таңы ата,
Кояш чыгып килә офыктан.
Юл буйлары яшел хәтфә-чирәм,
Җем-җем итеп тора саф чыктан.

Кошлар сайрый бигрәк моңлы итеп,
Йөрәкләргә керә моңнары.
Ишетелә таңда авылыбызга
Чылтырап аккан чишмә чыңнары.

Көтүченең чыбыркысы шартлый,
Яңгыратып авыл урамын.
Һәр йорт саен капка ачылганын,
И шатланып карап торамын.

Таң җиленнән килә бал исләре,
Мең төр чиргә дәва алырлык.
Бер таңнары өчен генә дә, дим,
Авылыбыздан китми калырлык!

## *Кояшлы яңгыр яуганда*

Җем-җем итеп җемелдәшеп,
Кояшлы яңгыр ява.
Аз яуса да, шул арада
Сафланып кала һава.

Яшәреп китә бакчада
Яшелчә-җимешләрем.
Игеннәр уңар, игенчем,
Бушка китмәс эшләрең!

Кояшлы яңгырлар явып
Торсын шулай гел генә.
Мул уңышлы булсын көзләр,
Ач булмасын ил генәм!

## *Соңгы өмет*

Читкә яшьли китеп адашканнар
Сагышлардан түгә күз яшен.
Төшләренә кереп йөди һаман:
Авыл урамнары ямь-яшел.

Хәтфә үләннәрдән йөгерә-йөгерә,
Каз бәбкәләр саклый балачак.
Таңнар аткач, тагын сагышлардан
Күңел мөлдерәмә тулачак.

Алар өчен сырхауларга дәва
Чишмәләрнең йотым суы да.
Бер туйганчы авыз итәр иде,
Ерагайган хәзер юлы да.

Кире кайту бүген мөмкин түгел,
Гомер калган көнләп санарга.
Ике метр җире туган якның —
Соңгы өмет инде аларга.

* * *

Искиткеч бер моң агыла,
Кемнең көе, кем җырлый?
Радиоалгыч яннарында
Берәү үксепләр елый.

Җыр — «Әнкәем догалары»,
Елатмаслык түгел һич.
Авторлары кемнәр дисәм,
Роберт белән Илгиз ич.

Моң агыла, берәү елый,
Эчен ут алды микән?
Әнкәсенең догаларын
Аламый калды микән?

* * *

Кыр кораблары басуда,
Эш кайный анда бүген.
Машиналар җилдерәләр,
Арбаларында — иген.

Игеннәр мул, югалтусыз
Җыеп алырга кирәк.
Яңгырлар гына яумасын
Инде, дип тели йөрәк.

Озакламый ил бурасы
Ашлыклар белән тулыр.
Икмәк булгач, ач булмабыз,
Җыр да, бию дә булыр!

## *Шатлык*

Ага чишмә чылтыр-чылтыр,
Яннарында таллары.
Суын алып авыз итсәң,
Яктыра күз аллары.

Чишмә буе таллары да
Җаннарга якын үзгә.
Әнә сандугач та нидер
Әйтергә тели безгә:

— И кешелек, туган җирдә
Синең күрер шатлыгың.
Саклап кына тот, кадерләп,
Талларыңның яшеллеген,
Чишмәләрнең сафлыгын!

## *Кырда*

Кырга чыктым, басу өсләренә
Сары җептән келәм чигелгән.
Келәм генәме соң, бүген монда
Зәңгәр күктән алтын сибелгән.

Тулган башаклардан учларыма
Алтын бөртекләре коямын.
Бөртекләрне хәтта алтыннан да
Кадерлерәк итеп тоямын.

Киң басулар буйлап кыр корабы
Дулкын ярып килә сак кына.
Табыннарны бизәр зур калачлар,
Таудай бәхет булыр халкыма!

## *Җанга рәхәт*

Алтыннарга манылгандай,
Күрәм иген кырын бүген.
Мул уныш булыр быел,
Гәрәбәдәй уңган иген.

Күз тимәсен, сөенепләр
Карыйм басу-кырларга мин.
Насыйп итсен югалтусыз
Ындырларга салырга, дим.

Башактагы һәрбер бөртек
Безнең яшәү чыганагы.
Икмәктән дә өстен башка
Җир йөзендә ни бар тагы?!

Кырга чыкты игенчеләр,
Кошлар сәлам җыры суза.
Җанга рәхәт — машиналар
Яңа уңыш төяп уза.

## *Бәхет нуры*

Кырга чыктым август иртәсендә,
Хуш ис аңкый иркен кырларда.
Кыр-кораблар килә тезелешеп,
Штурваллар тырыш кулларда.

Таң җилләре тулы башакларны
Талгын гына итеп тибрәлтә.
Тышта чиллә, көннәр бигрәк бөркү,
Игенчегә авыр, тирләтә.

Шул тир белән салган орлыклардан
Мул уңышлар җиткән өлгереп.
Күрәм, әнә, сезнең хезмәт бит ул,
Бәхет нуры тора бөркелеп!

* * *

Бәйрәм бүген, илдә бәйрәм бүген,
Игенчеләр, сезне данлыйбыз!
Игеннәрнең һәр бөртеге саен
Маңгай тире тамган — аңлыйбыз.

Шатланабыз, ничек шатланмыйсың,
Келәт тулы арыш, бодаем.
Ә шулай да, күңел шомлы бүген,
Илләр имин генә булып берүк,
Ризык итсен инде Ходаем!

## *Белем көне*

Белем көне бүген, бәйрәм көне,
Алтын көзнең алтын бәйрәме.
Шат елмаеп укучылар килә,
Кулларында — чәчәк бәйләме.

Каршы ала балкып, кояш сыман,
Укытучы апа, абыйлар.
Ялкау булсаң, хәтта кереп торма,
Кирәк түгел монда андыйлар.

Шар ачылган мәктәп ишекләре,
Хуш киләсез, рәхим итегез!
Белем баскычыннан армый-талмый,
Үргә кадәр менеп җитегез!

## *Көзге урман*

Ямь-яшел күлмәген чаган
Салып кызгылтын кигән.
Җимешләрен күтәрәлми —
Балан ботагын игән.

Сары чуклы шәльяулыгын
Бәйләгән дә ак каен,
Әллә каян балкып тора
Кояш нур сипкән саен.

Бар монда, бар яфракларның
Кызыл төсе, күрәне.
Ара-тирә яшелләре,
Бар бәсе һәм җирәне.

Кып-кызыл алкалар тагып,
Миләшләр тезелешкән.
Бер урманга гына Ходай
Күпме төсләр өләшкән.

Кадерен белсәк, байлыгы да
Барыбызга җитәрлек.
Көзге урман нинди гүзәл,
Соклангыч, искитәрлек!

## *Саубуллашу*

Көзләр җитте, көзен һаваларда
Болытлар да йөзә түбәннән.
Тирәкләрнең сары яфраклары
Очып-очып төшә тирәмнән.

Канатларын кагып саубуллашып,
Көньякларга кошлар юл ала.
Аерылышулары җиңел түгел,
Күңелләрдә моңсу уй кала.

Гомерләрне белеп буламыни,
Алда әле салкын олы кыш.
«Өмет белән яшә, — диләр кошлар, —
Язга кадәр инде хуш-хуш-хуш!»

## *Көньякка карап уйланам*

Моңсу көздә, җанга сагыш өстәп,
Кыр казлары очты көньякка.
Күзләремне яшь пәрдәсе каплап,
Карап калдым мин дә шул якка.

Авылымның көньягында зират,
Анда әткәм, әби-бабамнар.
Озатылды инде шул якларга
Күпме дуслар, күпме туганнар!

Язын кошлар кайтыр, ә үлгәннәр
Кайта алмый инде кирегә.
Кыр казлары булып алар рухы,
Кайтадыр ул, димен, бирегә!

* * *

Авылымны ямьгә күмеп,
Туйлар ясыйлар көздә.
Яшь парларны тәбрик итеп,
Кунаклар килә безгә.

Кыңгыраулы пар атларда
Килен төшә авылга.
Мәхәббәтләре чын булса,
Бирешмәсләр давылга.

Көз булса да, кулларында —
Аллы-гөлле чәчәкләр.
Өстәлләрдә туй ризыгы —
Баллы төшләр, чәкчәкләр.

Авылымны ямьгә күмеп,
Туйлар ясыйлар көздә.
Көн дә арта яңа гаилә,
Яшәрә авыл бездә!

## *Килен төшә*

Авылыма килен төшә
Кыңгыраулы атларда.
Урам тулып каршы ала
Танышлар да, ятлар да.

Йөзләрендә нурлар балкый
Яшь киленнең, — күрегез.
Бусагага мендәр салып,
Киленгә юл бирегез.

«Мәрхәмәтле бала булсын», —
Ана укый догасын.
Яшь гаиләгә бәхет теләп,
Ягез әле, дога кылыйк,
Китерик лә йоласын!

## *Каз өмәсендә*

Көзге муллык, көзге байлык —
Авылда каз өмәсе.
Кызлар килә каз йолкырга,
Шат күңелле һәммәсе.

Кызлар килә каз йолкырга,
Балкып тора йөзләре.
Кулларына күз иярми,
Бигрәк җитез үзләре.

И авылым, читкә китеп
Югалмасын кызларың.
Ямь китмәсен, ел да үссен
Оя-оя казларың.

## *Тере чишмә*

Салкын чишмә ага чылтыр-чылтыр,
Салкын кышлар каплый алмаган.
И бураным, һаман котырына,
Кар кермәгән бер җир калмаган.

И бураным, һаман котырына,
Ярый әле чишмәм туңмаган!
Бу дөньяда чишмә сукаедай
Татлы ризыккаем булмаган.

Ага чишмә, ага чылтыр-чылтыр,
Матурлыгын күреп куанам.
Тере чишмә кебек бит ул күңел,
Туңып кына калыр чакларымда
Якты өмет белән юанам.

## *Авылыма*

Туган авылым, Яңа Уртавылым,
Кояш илем минем, гөл илем.
Синдә тудым, синдә гомер итәм,
Назлап-назлап сөя таң җилең.

Кайгыларым, шатлыкларым синдә,
Мәгълүм аның сиңа барчасы.
Тирә-якларыңда елга-күлләр,
Урман, таулар, җимеш бакчасы.

Исемең дә җисемеңә килә,
Яңарасың, авылым, көн саен.
Сине ташлап читкә киткәннәр дә
Эзли кире кайтыр бер җаен.

Туган авылым, Яңа Уртавылым,
Колачың киң, әйдә, кайтсыннар.
Хаталарын аңлап, кире кайтып,
Бәхетләрен синдә тапсыннар!

## *Теләгем*

*Диләрә белән Рушат Назаровларга*

Борма-борма тормыш юлыгызда
Бер-берегезгә маяк булыгыз.
Җимешләре булып саф сөюнең,
Кызларыгыз тусын, улыгыз.

Арагызга сезнең бервакытта
Хыянәтләр керә күрмәсен.
Күңел гөлләрегез гомер буе
Яктылыкка гына үрләсен.

Кояш булып балкый йөзләрегез,
Бал аегыз сезнең бу айда.
Бал аедай үтсен гомерегез,
Ямьсезлекләр күп ич болай да!

## *Кыш килә*

Көннәр дә кыскарып бетте,
Җир-сулар туңган инде.
Бакчаларда коры сабак,
Чәчкәсе сулган инде.

Койган инде агачлар да
Соңгы яфрагын күптән.
Коела җиргә ак карлар,
Җем-җем килешеп күктән.

Карлар ява, җирне каплый,
Яусын әйдә, бит вакыт.
Заманалар нык болгавыр,
Хәерләре белән килсен,
Кыш килә ишәк шакып.

## *Үкенү*

Кышкы көндә салмак кына атлап,
Берәү бире килә юл буйлап.
Аяк асларында кар шыгырдый,
Әйтерсең бер үзгә көй уйнап.

Бире килә, янә ары китә,
Урамнарны ничә әйләнде.
Кесәсеннән кулъяулыгын алып,
Күзкәйләрен сөртеп сөйләнде:

Яшьли генә читкә чыгып киттем,
Өеп куйганнардай тау алтын.
Туган якның кары шыгырдау да,
Минем җанга, ай-һай, бик якын!

* * *

Көннәр буе буран котырына,
Көртләр күмә сукмак-юлларны.
Бураннарны ерып оча кошлар,
И кызганам, җәллим шуларны.

Тәрәз ачып кына дәшер идем,
Йорт кошлары түгел, кермәсләр.
Күңелемнең алар өчен әрнеп
Елаганын һич тә белмәсләр.

Кош — кош инде, ничек аңласын ул —
Кеше күңелен кеше нишләтә?!
Рәнҗетәләр кайчак күңелеңне,
Гел изгелек кенә эшләп тә...

## *Түгелсен яшь*

Колак булгач ишетәсең —
Әйтәләр авыр сүзләр.
Ачысыннан көтмәгәндә
Яшьләнә кайчак күзләр.

Ир-егеткә яшь күрсәтү,
Килешкән эш түгел дә,
Кара болытлар куерып
Куйгалый шул күгемдә.

Төннәр буе үксеп яттым
Менә тагын бүген дә.
Түгелсен, әйдә, яшьләрем,
Ул кешегә булган ачу
Яшәмәсен күңелемдә!

* * *

Сәгать угы уникедә,
Хуш киләсең, Яңа елым!
Якты өметләрем баглап,
Чыгам сиңа, Яңа юлым!

Зур өметләр белән чыга
Яңа елга бүген халкым.
Аклансын бар ышанычы,
Өшетмәсен җанны салкын.

Тормыштагы бар авырлык
Иске елда торып калсын.
Яңа елда яңа бәхет
Күңелләрне биләп алсын.

## *Яңа ел иртәсе*

Җемелдәшеп сибелә ап-ак карлар,
Нинди гүзәл мәле ак кышның.
Урамнарга чыксам, саф һавасын
Туя алмый сулыйм мин тышның.

Тыш һавасы җанга шундый рәхәт,
Тын юллары китә киңәеп.
Сәлам бирә әнә тупыллар да,
Колачларын миңа киң җәеп.

Бөтерелеп яуган мамык карлар
Үбеп-үбеп үтә битемнән.
Әйтерсең дә шушы минутларда
Бәхетлерәк беркем юк миннән!

Җемелдәшеп сибелә ап-ак карлар,
Онытылдым кереп аклыкка.
Яңа елның һәр сәгатен, көнен
Юрауларым бары шатлыкка.

## *Җырың кайта*

*Авылдашым, шагыйрь*
*Гайнан Әмири истәлегенә*

Авылыңны сагынып кайта идең,
Тирәгенә кошлар кайтканда.
Кар сулары эчеп, болыннарда
Умырзая чәчәк атканда.

Авылыңны сагынып кайта идең,
Күкрәп үскән чакта башаклар.
Җаннарыңнан шигырь булып чыкты
Авылыңда йөргән шул чаклар.

Син юк инде, шагыйрь, бүген килеп,
Авыл халкы сине сагына.
Җылы язның сандугачы булып,
Җырың кайта туган ягыңа!

* * *

Авыл юллары таш, асфальт,
Сукмаклары хәтфә чирәм.
Шау чәчәктә алмагачлар,
Нурлар чәчә бөтен тирәм.

Бала-чага тавышыннан
Нур өстенә ямь өстәлә.
Тагын шуны әйтә алам
Шигыремә мин өстәмә:

Һәрбер йортка газ-су кергән,
Каладан һич юк аерма.
Авыл сүзен ишетүгә,
Канәгатьсез йөз җыерма.

Яшьләр китми, яши алар,
Туган җирнең кадерен белеп.
Болай булгач ышанамын:
Авылым калмаячак үлеп!

## *Карлар ява*

Ябалаклап ап-ак карлар ява,
Тирә-юньдә шундый матурлык!
Мамыктай пакь шушы ак карларны,
Түшәк итеп кенә ятарлык.

Шушы кадәр аклык-сафлыкларга
Басарга да хәтта кыймассың.
Бәс ягынган агачларны күзләп,
Гомерең буена да туймассың.

Карлар ява, ап-ак карлар ява,
Яусын әйдә, яусын шатлыкка.
Тормыштагы булган пычраклыклар
Бетсен әле күмелеп аклыкка!

## *Язгы җыр*

Мартның беренче көненнән
Яз төсе керде көнгә.
Күзем төшеп, хәйран калдым
Тәрәз төптәге гөлгә.

Кичә генә юк иде бит,
Чәчәк аткан бүгенгә.
Гөлне күреп сокланудан
Нидер булды күңелгә.

Йөрәк хисләрен тыялмый,
Кошлардай кагыну бу!
Инде кабатланмый торган
Яшьлекне сагыну бу!

## *Яңа яз җитте*

Карлар эри, тып-тып тамчы тама,
Гүя дәртле йөрәк кагышы.
Ярларыннан ташкан елгаларның
Ишетелә шаулы агышы.

Бөреләнә инде тал-тирәк тә,
Сусагандыр былбыл җырына.
Күз алдымда гөлләр тармаклана,
Үрмәлиләр кояш нурына.

Сокландыргыч язгы бу мизгелләр,
Күңелемне кабат яшәртә.
Юк, әйтәлмәм, дөньям, туйдым, диеп —
Әллә ничә гомер яшәп тә.

* * *

Яз килгән, яз, урамнардан
Гөрләвек шаулап ага.
Сыерчыклар кайтып җиткән,
Шатлыктан канат кага.

Авылкаем аларның да
Туып-үскән ягы бит.
Бу мизгелләр кошкайларның
Иң бәхетле чагы бит.

Әнә күрше әбием дә
Туган җиренә кайткан.
Йөзләре балкый, нур чәчә,
Гүя, гөл чәчәк аткан!

## *Туган авыл көтә*

Кошлар җырлый иртә-кичен,
Сагынышып кайтканнар.
Туган җирләренә кайтып,
Ояларын тапканнар.

Язлар саен кайта кошлар,
Сагынып кайта оясын.
Кош моңнарын тыңлаганда,
Җанга рәхәт тоясың.

Авыллардан киткәннәрне
Күрсәң, рәнҗеп куясың.
И, кешеләр, нишләдегез,
Туган җирдән туясыз?

Киткәннәр дә кошлар кебек,
Кайта да, кире китә.
Ә туган җир, туган авыл,
Аларны бит бөтенләйгә
Кайтырлар диеп көтә.

## *Бәйрәм*

Борынгыдан калган матур йола —
Сабантуйга әйбер җыялар.
Яшь киленнәр чиккән сөлгеләрне
Колгаларга бәйләп куялар.

Бәйрәм бүген, гармун тавышларын
Ишетүдән күпләр моңая.
Киленнәрнең сөлгеләрен күреп,
Авыр сулап, чибәр әби әйтте:
«Их, яшьлегем язы, син кая?»

Әйтеп куйды шулчак чибәр бабай,
Кукрәгендә ярсып йөрәге:
«Беркемгә дә һич тә бил бирмәдем,
Булдым һәрчак мәйдан терәге!»

Борынгыдан калган матур йола —
Колгаларга әйбер бәйлиләр.
Кыңгыраулар чыңлап дугаларда,
Сабантуйга безне әйдиләр!

## *Кайтыгыз*

Сабантуйга кайткан авылдашлар,
Бөтенесе якын, үз кеше.
Әле берсе килеп кулны кысты,
Күптән киткән иде бу күрше.

Гомер иткән җирен мактаса да,
Яннарыма утырып бик озак,
Әмма, күреп торам, әнә аның
Күзләрендә сагыш, моң-газап.

Читтәгеләр, аңлыйм хәлегезне,
Туган якта ярты җаныгыз.
Бәйрәмнәргә түгел, бөтенләйгә —
Оя кору өчен кайтыгыз!

## *Алдыңда — зур юллар*

Соңгы кыңгыраулар чыңы,
Артта мәктәп елларың.
Алда синең иксез-чиксез
Дәрьядай киң юлларың.

Югары уку йортлары
Көтә сине, китәрсең.
Киләчәгең үз кулыңда,
Үзаллы хәл итәрсең.

Син бәхетле, сау-сәламәт,
Ата-анаң бар, тигез.
Алар булу синең өчен
Киләчәккә нык нигез.

Хезмәтне сөй, әйтәләр ич:
«Эш сөйгәнне ил сөя».
Язык эштән читләп йөре,
Бәхетеңә бул ия!

## *Булачак әни*

Биш-алты яшьлек кыз бала
Йөри коляска этеп.
Ак биләүгә биләп салган
Курчагын сабый итеп.

Мендәрләрен җайлап сала,
И иркәли әнкәсе.
Пышылдап кына сөйләшә,
Бала йоклый, янәсе.

Сизелми дә узып китәр
Бер унбиш ел чамасы.
Булыр бу кыз бик бәхетле
Сабыйларның анасы!

* * *

Болында каз бәбкәләрен
Саклый җиткән бер кыз бала.
Үзе сылу, үзе җитез,
Йөгерә-йөгерә җимнәр сала.

Тилгәннәр түгел, бер егет
Карашларын төби читләп.
Кыз да карап-карап ала,
Хисләр таша, булмый бикләп.

Ни әйтәсең, яшьләр җиткән,
Ярсып тибә ике йөрәк.
Бәбкәләр, тизрәк үсегез,
Күзгелеккә апагызга
Бирнәгә пар мендәр кирәк!

## *Язгы чәчәкләр*

*Карам Әһлиуллин көе*

Язның тәүге чәчәкләрен
Саф кызларга охшатам.
Шул сафлыкның кадерләрен
Белмиләр бит, шаккатам.

Бик күпләре күзне көтми,
Бигрәк иртә сула шул.
Кызлар — сафлык, язлар — чәчәк
Белән матур була шул!

## *Кыюсыз егет сүзе*

Әйтәсе килгән сүзем бар,
Бүген дә кыялмадым.
Кайчаннар тормышка ашар
Бу матур хыялларым?

Озатыплар йөргән булам,
Үтә бит гомеркәем.
Башлап әйт үзең ичмасам,
Кызган ла бәгыркәем!

«Яратам бит, яратам бит,
Яратам бит, гөлкәем».
Әйт-т-т-т-ем!

## *Чәчәк өзгән егеткә*

Егет кеше чәчәкләрне
Өзеп алды кулына.
Нигә генә өзде икән,
Ташлар булгач юлына?

Шушы егет үтеп бара,
Янында сылу бер кыз.
Кычкырасым килде аңа:
«Кыз баланы да чәчәктәй
Өзә күрмә син, котсыз!»

* * *

Йөзләреңә карап-карап куям,
Әллә ялгыш күрәм, син түгелме?
Чибәрлегең әле кайчан гына
Әсир итә иде бит күңелне.

И кыз бала, язда кырау төшкән
Чәчәкләргә охшап калгансың шул!
Шулай булмый, син дә авызыңа
Агу тулы сигар алгансың шул!

## *Әрнеп язылган хат*

Сөйдем сине, янып-шашып сөйдем,
Таңнар аттырдык без гел бергә.
Син дә әйттең: «Аккош мәхәббәтен
Саклыйк, иркәм, саклыйк гомергә!»

Көн яктысы сүнгән сыман булды,
Синең хакта хәбәр ишеткәч.
Нигә мине үзеңнеке иттең,
Башкаларны да син үз иткәч?

Минем намусымны таптап үтеп,
Соң син нинди рәхәт күрерсең?
Кыз баланың кайнар яше өчен,
Ходайга ни җавап бирерсең?!

Яшьлегебез шундый матур иде,
Әрнү белән үтеп китәрме?
Сине, бәлки, гафу итәрмен мин,
Тик мәхәббәт гафу итәрме?

* * *

Минем янда сылу бер кыз бала,
Толымнарын салган иңенә.
Сафлык кына бөркеп тора аннан,
Капмаган ул заман җиленә.

Эчкән, тарткан исләр килми кыздан,
Килә бары чәчәк исләре.
Ходай биргән аңа чибәрлекне,
Карап туйгысыз бит-төсләре!

«Сигаралы кызлар тирәсеннән
Һәрчак, — ди ул, — читләп үтәмен».
Башкаларны да мин аның кебек
Булырлар дип өмет итәмен!

## *Кызларга*

Әй, кыз бала, беркөн генә
Берәүгә гашыйк идең:
«Хәзер бары аны гына
Ярататачакмын!» — дидең.

«Сөйгән кешем куенында
Аттырдым, — дисең, — таңнар.
Мәңгелеккә аерылмаска
Кушылган тәннәр, җаннар!»

Инде бүген шул кешеңнән
Син үзең баш тартасың.
Имеш, хәзер аны түгел,
Башканы ярарасың.

Үзеңчә ничек уйлыйсың,
Ярата беләсеңме?
Әллә син мәхәббәт дигән
Хисләрдән көләсеңме?!

## *Гөлбакчада*

Бакчадагы гөл чәчәген
Җилләр өзеп төшерде.
Нәкъ шулвакыт гөлбакчага
Кыз бала йөгереп керде.

Гөл чәчәген кызганудан
Мөлдерәп акты яшькәе,
Әле болай гына елый,
Бәләкәй шул яшькәе.

Аңламый шул әле сабый
Тормышта ни булганын.
Теләмәс идем кызларның,
Шушы чәчәк гомередәй,
Вакыт җитми сулганын.

* * *

«Авыл, диеп миннән көлмәсеннәр,
Сүгенәмен төрле телләрдә.
Миндәй оста итеп булдыралмый,
Кызлар түгел, ир-егетләр дә!

Шәһәр кызларыннан мин киммени,
Хәмер дигәннәрен какмаска!
Бот төбеннән генә итәк киеп,
Авызыма сигар капмаска!

Төн буена урам эте кебек,
Этлек эзләп нигә чапмаска?!
Бала табып, хастаханәләргә
Нигә әле ташлап кайтмаска!

Киләчәктә наркотикларын да
Икеләнеп тормый кадармын.
Шәһәр кызларыннан ким булмаска,
Мин барыбер җаен табармын!»

Ялгыш кына ишетәмдер моны,
Авыл кызы, юк, бу син түгел!
Җуелмаган гүзәллегең белән
Үрнәк булып шәһәр кызларына,
Калуыңны тели бит күңел!

* * *

Зәп-зәңгәр иде күк йөзе,
Таң атканда сызылып.
Ни арада офыклардан
Болыт чыкты сузылып?

Тирә якларны каплады
Күктә болыт, куерып.
...Ишеткән авыр сүзләрдән
Калды күңелем уелып.

Җил чыкты, болыт таралды,
Килсә дә нык каралып.
Күңелдәге авыр сүзләр,
Күктәге болытлар кебек,
Тиз бетми шул таралып.

* * *

Берәм-берәм китәбез шул,
Мәңгелек түгел беркем.
Килер ул әҗәл дигәнең,
Мине дә алыр беркөн.

Бәлки бүген килеп алыр,
Бәлки әле күп елдан.
Тик, Ходай, соңгы көнгәчә
Аерма мине, аерма,
Иманымнан, хак юлдан!

* * *

Син чыгасың капка төпләренә,
Ямансулап иртә-кичләрен.
Синең моңсу йөзләреңне күреп,
Өзгәләнә минем эчләрем.

«Көтмә инде, кайтмый!» — дия алмыйм,
Әйтмәсәм дә, үзең беләсең.
Ничәнче ел инде каберенә
Син чәчәкләр салып киләсең.

Канаткае каерылган кошкай
Хәлләренә калдың бик иртә.
Вакыт җиткәч, әҗәл дигәнеңә
Булмый икән куеп һич киртә.

Киткәннәргә теләү генә кала
Оҗмахларга имин үтәргә.
Калганнарга бөтен авырлыкны
Җиңә-җиңә сабыр итәргә!

* * *

Ничек кенә аны мәсхәрәләп
Тукмаганнар, канын койганнар,
Алалмагач җанын, кулларыннан
Түшәмнәргә асып куйганнар.

Максатына ирешмәгәч, дошман
Күзе тонып тәмам котырган.
Утлы кисәү басып тәннәренә,
Җанын исә бозга катырган.

Имгәнмәгән җире калмаса да,
Бу михнәттән исән чыгалган.
Ләкин илгә кайткач аны бер сүз
Мәңгелеккә сугып егалган: «Әсир!»

* * *

Өч күбәләк очып уйный —
Нигә парлы түгелләр?
Парсызлыкны күреп, хәтта
Боегып калды гөлләр.

Килеп җитте дүртенчесе,
Бу хәлне белде, бугай.
Тагы да ямьләнеп китте
Гөлле-чәчәкле тугай.

И, сокландгыч күбәләкләр,
Әнә, очышып уйный.
Бу тормышны ямьсезләгән
Ялгызлык булмасын иде,
Диеп күңелем уйлый!

* * *

Кичә генә кап-карадан идең,
Инде менә яшел кигәнсең.
Син, Җир-анам, бер могҗиза инде,
Башка сиңа нәрсә диярсең!

Күпме миллион, миллиард җан иясен
Асрарга көчең җитәрлек.
Капкан тәгамнәрнең һәркайсысын
Син бирәсең, исләр китәрлек.

Ашларыңа ташлар атабыз шул,
Әнә шунысы бигрәк читене.
Өсләреңдә синең туплар шартлый,
Кан-яшь юа бүген битеңне.

Сабырлыгың, синең сабырлыгың
Әнкәйләргә генә хас инде.
Йөзләреңдә күпме тирән сырлар,
Бирешмисең — тагын яз килде!

## *Чишмә елый*

Чишмә чыңлый, чишмә гүя елый —
Күкрәп үскән талын кисkәннәр.
Алар да бит якты дөньялыкта
Яшәр өчен тырышып үскәннәр.

Яшел таллар! Кемнең явыз эше,
Кем күтәргән микән балталар?
Экраннарда күргән яу кырларын
Хәтерләтеп алар яталар.

## *Җиңәргә!*

Шундый чаклар була бик еш кына,
Дөньялыктан туеп куясың.
Дуамаллык белән җиңел уйлап,
Җаннарыңны, кешем, кыясың.

Шатлыклардан гына тормый тормыш,
Төрле чаклар булып куйгалый.
Әле күңел көзең аяз булса,
Әле кара болыт оялый.

Тормыш булгач, була төрле чагы,
Авырлыклар төшә иңнәргә.
Бу дөньяда без бит кунак кына,
Авырлыкны кирәк җиңәргә!

* * *

Кеше гомере, гүя, чәчәк гомере,
Чәчәкләрнең күрке — матурлык.
Шушы чәчәк кенә гомереңдә
Яшә әле кылып матурлык!
Шушы булыр синең батырлык!

## *Юлдагы уйлану*

Юл буена ук куелган
Тимердән бер чардуган.
Аңлашыла: бу урында
Зур бәхетсезлек булган.

Кемнәрнеңдер газизенең
Гомерләре өзелгән.
Чардуган эчендә таш бар,
Шундый сүзләр тезелгән:

«Башыма җитте эчкелек,
Руль артында эчмәгез.
Гомерегезне кызганыгыз,
Минем хәлгә төшмәгез!»

Юл буенда чардуганнар,
Искәртү ясый алар,
Фаҗигасез булсын өчен
Һәрвакыт безнең юллар!

* * *

Шәһәрдән авылга кайтты
Нәнәсенә кунакка.
Оныгының кайтканы юк
Иде күптән бу якка.

Кочаклашып күрештеләр
Нәнәсе белән оньк.
Шулай булмый, берсен-берсе
Сагынганнар шул бик нык.

Нәнәсе сөйли татарча,
Хәлләрен сораштыра.
Малай бер җавап та бирми,
Күзенә карап тора.

Татарча сөйләшә белми,
Татар баласы булып.
Аларны күзәтеп торам,
Әрнеп, күңелем тулып.

## *Яралы күңеле*

Әнкәсенә сырпалана
Нәни песи баласы.
Теле белән ялый-ялый,
И иркәли анасы.

Бу күренешне күзәтә
Ымсынып ятим малай.
Аның да яратыласы
Бик тә килә бит шулай.

Әнкәсе аны тугач та,
Карамый, ташлап киткән.
Бу бәхеттән мәңгелеккә
Сабыен мәхрүм иткән.

## *Югалту*

Песи баласы югалды,
Ахрысы, кемдер алды.
Анасы белеп бу хәлне,
Кара кайгыга калды.

Ашамас булды бер тәгам,
Гел кычкырып эзләнә.
«Күрмәдеңме син?» — дигәндәй,
Өзелеп карый, әнә.

Моңсу, яшьле карашларын
Тора ул төбәп күзгә.
Балаларын мәңгелеккә
Югалткан барлык аналар,
Сабырлык телим Сезгә!

* * *

Бер ирне кулга алдылар,
Кыйнаганга анасын.

Актык көче белән торып,
Култамгасын куя ана,
Коткарырга баласын.

Оныклар бар! Ана сизә
Улының да киләчәктә
Үз хәлендә каласын...

* * *

Ир белән хатын талаша,
Гүя тетри Җир шары.
Уктай атыла сүзләре,
Әйтелә анда бары.

Куллар да эшкә тотына,
Оча савыт-сабалар.
Кыз-уллары куркуыннан
Урамга ук чабалар.

Төн җитүгә калтыранып,
Балалар өйгә кайта.
Ата-ана кочаклашып, —
Берни юк, йоклап ята.

Гомер уза, ир һәм хатын
Әби-бабай булалар.
Килен, малай арасында
Хәзер бураннар еш була,
Картлар тышта куналар.

* * *

Җирне тырный-тырный елый —
Дәрья аның күз яше.
Өзгәләнә хатын җаны,
Дөнья куйды иптәше.

Авыл халкы чыш-пыш килә:
«Бик яшь калды бичара.
Тиңе чыкса, янә чыгар,
Табалмас башка чара».

Бер тол хатын әрнү катыш
Әйтеп куйды шул ара:
«Беренчесе булмый шул ул,
Хет меңгә барып кара».

* * *

Шакыдың, рөхсәт сорадың,
Ачтым ишек келәсен.
Әйттең: «Күптән очрашмадык,
Килә сине күрәсем».

Син дә хаклы, эт-мәчедәй
Күпме була яшәргә!
Бик авырлык белән генә,
Базнат иттем дәшергә.

Теләсәң дә, сүз ярасы
Онытылмыйдыр, күрәсең.
Ачуланма, мин ачалмам
Йөрәгемнең келәсен!

## *Эш узгач*

Гөрләп яшәр чакта алар
Һич татулык белмәде.
Урамнарга чыгып хатын:
«Катсын, — диеп теләде. —

Изалар чиктем гомергә,
Бер рәхәт тә күрмимен.
Җәфалауларыннан качып,
Кемгә генә кермимен!»

Килде ул көн: ире — вафат,
Кан-яшь түгә шул ханым.
Фәрештә булган икән ич
Хәләл җефете аның!

## *Ялгыз әби*

Ару-талуларын белми,
Җим ташый кош баласына.
Нарасые томшыккаен
Ачып тора анасына.

Ялгыз әби агачтагы
Кошлар оясына бага.
Кошчыкларны күреп, аның,
Сагышлардан күңеле тулып,
Күзләреннән яшьләр ага.

* * *

(Бала табарга теләмәүчеләр бар)

«Бәхетле син», — диләр аңа, —
Өс-башларың бик бөтен.
Сөбханалла буй-сыннарың,
Күз тимәсен төс-битең.

Авызың тулы алтын теш,
Балда-майда йөзәсең.
Йортың нинди, машинаң бар,
Дөньяларны гизәсең.

Ялгызың гына түгелсең,
Гомер иткән ирең бар.
Чит илләрдә яшәмисең,
Туып-үскән җирең бар».

Бөтенесе җитеш сыман,
Шушы буламы бөтен?
Бәхет, дисез, шул бәхетме —
Сабыен түгел, хатын кич
Җитәкләп чыга этен.

## *Каргамасын язмышын*

Хәлкәе җиңелдән түгел,
Ул көне-төне бәйдә.
Көзен, кышын гына түгел,
Бәйдә шул яз да, җәй дә.

Муенында — тимер чылбыр,
Өзәрлек түгел аны.
Бер ireккә чыкканы юк,
Түзгәч, түзә эт җаны.

Бәйдә көе хуҗасына
Файда эшләп яши эт.
Язмыш чылбырлаганда да,
Кешеләр дә бу тормышта
Матур эшләр кыла бит!

* * *

Сабаклары яшел дә соң,
Чәчәкләре шиңгән шул.
Бирешмәскә тырышсаң да,
Салкын көзләр җиңгән шул.

Бирешмәскә тырышсаң да,
Бәсләр кунган чәчләргә.
Күзләр күрми, теш коелган,
Дәрманнар юк эшләргә.

Кулларыңнан әйберләрең
Төшеп китә идәнгә.
Хәтер кала балаларың:
«Ял ит инде», — дигәнгә.

Җиткән гомер көзләреңне
Санлыйсың килми әле.
Күңел генә яшь калганын
Аңлыйсың килми әле!

* * *

Йөрешләре бик тә сүлпән,
Чак-чак тигезлек саклый.
Шулай булмый, картайган ич,
Инде туксанны ваклый.

Кибеткә китеп бара ул,
Кирәк-ярагы беткән.
Балалары кайтмады шул,
Хәтсездән инде, күптән...

Аны күргәч тә артыннан
Чыгып йөгерде энем.
Уйлагандыр ул, минем дә
Җитәр, дип, картлык көнем!

## *Урам эте*

Тәрәзәдән карап торам,
Урамда йөри бер эт.
Иснәнеп чыга һәркемнең
Капка төбенә кереп.

Әнә тагын берәү килә,
Эт түгел, монсы кеше.
Ишегеннән дә керетми,
Куып чыгарды күрше.

Безнең дә ишекне какты,
Эчәргә эзли икән.
Әзмәвердәй бу иркәйнең
Ояты качты микән?

Мөселман кешесе бит ул,
Белә — ураза ае.
Хәмергә сатар анасын,
Килеп чыкса бер җае!

## *Давыллы чак*

Нинди тавыш, нинди гауга,
Кем талаша?
Кычкыра ханым иренә:
«Син — алаша!»

Бар дөньялары да җитеш,
Йортлар яңа.
Бөтен яклап ярдәм итә
Ире аңа.

Нәрсә җитми соң боларга,
Хәйран калам.
Бу хатынның сүзләренә
Колак салам:

«Бар чыгып кит, күземә дә
Һич күренмә!
Яннарымда җан көеге
Булып йөрмә!

Бер ярдәм итим, димисең,
Тик ятасың.
Көн дә убыр, алкаш, эчеп
Син кайтасың.

Утыным да, печәнем дә
Әзер кышка.
Рәхәтләнеп яшәрмен мин
Синнән башка!»

Дип иренә акырды ул,
Нидер орды.
Күрше апа да боларны
Тыңлап торды.

Өзелгәндәй булды шулчак
Йөрәк кылы.
Аның да бит буй җиткергән
Бар дүрт улы!

## *Сәбәп*

Табып кырык дус-ишләрен,
Кунакка дәште бер ханым.
Ун көн элек туган көнен
Юган идек бит без аның.

Аннан кызы туган көнне,
Чәкәштереп, бәйрәм иттек.
Елы тулган, каенатасын
Шунда искә алып үттек.

Тагын нинди бәйрәм икән,
Әллә ире туган көнме?
Бүләк алып барыйм микән,
Соң котларга анда кемне?

Баргач күрермен әле, дип,
Конверт белән акча алдым.
Бу мәҗлес соң ни сәбәпле,
Моны белгәч хәйран калдым.

Эчкелек чиреннән ире
Дәваланып чыккан кичә.
Шуны юу максатыннан
Ханым оештырган кичә!

* * *

Зурларга охшарга теләп,
Бала рюмка тота.
Алар белән чәкәштереп,
Тәмле, газлы су йота.

«Карале, минем дә улым
Үскән!» — дип ана көлә.
«Хәзергә көләсең дә соң,
Азак еламассың микән
Ханым?» — диясем килә.

## *Ямьсезлек*

Урамда икәү талаша,
Әйтелә авыр сүзләр.
Чәч-башлары тузып беткән,
Акаеп тора күзләр.

Бер-берсенә юл куймыйча,
Бик озак алыштылар.
Телләре арып туктагач,
Артларын чабыштылар.

Гыйбрәт алып үтсә иде
Күпләр болар янынннан.
Алар бит ике бөртекләр
Бер ана карынынннан.

## *Эт малае*

«Эттән туган, — дип орыша
Бер ханым үз баласын, —
Нигә кәнфитне шкафтан
Гел рөхсәтсез аласың?»

Гаҗәпләнеп карап торам:
Кайсысы охшый эткә?
Ханым үзе дә күренә
Ярыйсы төскә-биткә.

Ау-һау килеп тормый ир дә,
Эткә охшамый алай.
Менә мәзәк, болай булгач,
Кемнән туган соң малай?!

## *Шаһи*

Алыпсатар булып, Шаһи
Бай кешегә әйләнде.
Торган хатынын аерып,
Бер яшь кызга өйләнде.

«Колы итмәкче була! — ди, —
Шуңа аердым аны!»
Монсы белән дә тормады,
Күбәя хатын саны.

Килә тора, китә тора
Хатыннар берәм-берәм.
Шаһиның җыйган байлыгы
Тузандай оча, күрәм!

Калмады торыр җире дә,
Кияренә, ашарга.
Дәрман бетте, булган эшен
Туры килде ташларга.

Иң беренче хатынына
Әйләнеп кайтты Шаһи.
«Колың булырга әзермен,
Кертче!» — дип ишек шакый!

## *Бүгенге көн*

Зәңгәр экранда, күр, әнә,
Шәһәрнең зур чүплеге.
Карашымны җәлеп итте
Анда кошлар күплеге.

Каргасы да, чәүкәсе дә,
Чыпчыгы да бар анда.
Берәр генә түгел алар,
Йөзәр, меңәр — күп санда.

Кошлар гына түгел монда,
Этләр йөри эзләнеп.
Алай гынамы соң, әнә,
Бөкрәеп беткән карчык,
Ризык эзли тезләнеп...

* * *

«Башым чатный, бир йөз грамм!» —
Ди бер ир хатынына.
Тиңли ул хәләл җефетен
Дөньяның алтынына.

«Жир шарында да юк синең
Кебек тугры, саф бичә.
Терелт инде, җанкисәгем,
Күбрәк салганмын кичә!»

Ишеткән идем бу ирнең
Ниләр әйткәнен кичә.
Тугры ласа кичә генә
«Уйнашчы» булган бичә!

* * *

Анасы пенсия акчасын
Эчәргә бирмәгәч улына,
Күзенә ак-кара күренми,
Исерек бер егет тузына.

Һәр әйткән сүзләре җирәнгеч,
Анага — «тоттыра», «каптыра».
Төрлечә куркытып, барыбер,
Мәҗбүри яртылык таптыра.

Ишетеп, күзәтеп бу хәлне,
Кызыллык йөгерде йөземә.
И тәңрем, нигәләр я акыл,
Я җәза бирмисең үзенә?

* * *

Әзмәвердәй ир зарлана:
«Ни көнгә калдым, кара.
Асылынып кына үләм,
Калмады башка чара!»

Аягын сындырган икән,
Гипска катырганнар.
Берничә айдан төзәлер,
Дип әйтеп кайтарганнар.

Инде гомерем буена
Урын өстендә үзем.
Тыңлап-тыңлап тордым да мин
Шушы елакның сүзен,

Әйттем, ничек түзмәк кирәк:
«Кайгың бигрәк авыр шул!
Үтеп китәр бәлагә дә
Сайлыйлармы соңгы юл?!»

## *Хат килгәч*

Күрше әби кергән атлый-йөгерә,
Йөзе нурга чумган, шундый шат.
Кулларына тоткан ачык конверт,
Ә эчендә аның бер бит хат:

— Кызымнан хат килгән, укы, балам,
Хәлкәйләрен белимче тизрәк.
Хәбәрләрен ишетмичә торсам,
Тынычсызлана бит бу йөрәк.

Һәрбер сүзен дикъкать белән тыңлый,
Кат-кат укыйм аның көенә.
Баласының исәнлеген белгәч,
Ана кабат-кабат сөенә.

Гадәти хәл — авыл балалары
Буй җитүгә читкә китәләр.
Ә нигә соң ата-аналарын,
Бик күпләре әле, бик күпләре
Сәлам хаттан мәхрүм итәләр?!

## *Күршеләр*

Айлар буе бер-беребезгә
Кәлимә сүз дәшмибез,
Араларны читән аера,
Тәрәлешеп яшибез.

Күрше хакы — тәңре хакы,
Дисәләр дә, эре без.
Берең олы, икенчебез
Кече булмый йөрибез.

Юкка-барга, сүзгә килеп,
Рәнҗетәбез күңелне.
Без соң фани дөньялыкта
Кунак кына түгелме?!

## *Бала күңеле — далада*

Балдай татлы, дип иркәли
Ана газиз баласын.
Сизә микән ул бервакыт
Ялгыз торып каласын?

Балам, диеп күп аналар
Тәгамнәрен өзәләр.
Карт көнендә, ялгыз калгач,
Дәшми алар, түзәләр.

Ә балалар беләме соң
Аналарның кадерен?
Бар бит адәм актыклары,
Хәтта белми каберен.

Әйтегез соң, каян килә
Бу кадәрле явызлык?
«Бүләк» итә күрмә, бала,
Карт анаңа ялгызлык!

## *Ак өметем*

Пар сандугач сайрый бакчабызда,
Бер тирәктә янәш сыенып.
Төннәрен дә алар серләшәләр,
Ай нурына бергә коенып.

Авыр язмыш җиле икебезне
Ике ярга илтеп ташлаган.
Кошлар кебек гел сайрашып яшәү
Хыяллары чынга ашмаган.

Көннәремдә истә, ә төннәрен,
Төшкә кереп, ничә уянам.
Тик шунысы: әле киләчәк бар,
Ак өметләр белән юанам!

* * *

Нинди рәхәт, дөнья белән  
Бергә шатландым, көлдем:  
Бүген генә авылыбызда  
Бер сабый дөньяга килгән —  
Шуны ишетеп белдем!

* * *

*Хатын-кызларга*

Тормышны син төзисең бит,  
Җимермисең.  
Килгән авырлыкларга һич  
Җиңелмисең.  
Авырлыкны җиңәсең гел  
Җырлый-җырлый.  
Шатлыкларны каршылыйсың  
Елый-елый.  
Елатса да, һәрчак сиңа  
Шатлык килсен.  
Тормышка гүзәллек биреп,  
Көл, елмай син!

## Гашыйк егеткә

Төнге күктән йолдыз алам, диеп,  
Талпынасың, егет, күкләргә.  
Кыз күңеле кылдай нечкә бит ул,  
Якты йолдыз — бәхетен көткәндә.  
Кыз күңеле кылдай нечкә бит ул,  
Уйламыйча гына йогынма.

Туар көндә кояш вәгъдә итсәң,
Әйләндермә берүк уенга.
Кояш, йолдызларны үрелеп алып
Бирәлмәссең, җитмәс буйларың.
Сөйгәнеңә җан җылыңны бир син,
Якты булсын һәрчак уйларың!

* * *

*Ир-егетләргә*

Җаннымы, төнге күкнеме
Телгәли утлы яшен.
Сорамагыз егетләрнең,
Ничәдә, диеп яшен.
Сорамагыз егетләрнең,
Картаямы, дип, җаны.
Картайса да югалмый ул
Булган егетнең даны!
Кирәк икән — ил чакыра,
Сорамый аның яшен!
Утлар-сулар кичә егет,
Күрмәссең тамчы яшен!

## *Хөрмәтебез — сезгә*

Хатын-кыз ул — тормыш матурлыгы,
Бар дөньяның яшәү терәге.
Шушы гүзәллектән ялкын алып,
Дөрләп яна ирләр йөрәге!
Хөрмәт белән Сезгә, хатын-кызлар,
Башыбызны түбән иябез.
Безнең йөрәк ялкыннарын шулай,
Мәңге сүндермәгез, диябез!

## *Моң*

Гармун тавышы ишетәм,
Моң агыла бер өйдән.
Бар булмышымны оныттым
Илаһи бу моң-көйдән.
Сагындырган гармун моңы,
Күптәннән ишетмәдем.
Көй беткәнче аерылып,
Өй яныннан китмәдем.
Көй тынса да, колагымда
Яңгырады озак чыңы.
Әткәм дә гармунчы иде,
Йөрәктә һаман моңы!

## *Тирәк*

Алларымда җил-давылга
Бөгелә бер тал-тирәк.
Бу кадәрле давылларга
Сынмый түзәргә кирәк!
Бөгелсә дә, сыгылса да,
Түзә шул, түзә тирәк.
Әйтерсең, ул авырлыкны
Күп җиңгән минем йөрәк!

* * *

Каршыладык җәйнең тәүге таңын
Синең белән бергә болында.
Хыялларда түгел, бүген өндә
Синең кулың — минем кулымда.

Әллә инде тәбрикләве микән,
Таң җилләре безне иркәли.
Күзләребез күзгә төбәлгәннәр:
«Аерылмыйк мәңге, иркәм», — дип.
Ишетәсеңме, сандугачлар җырлый,
Талгын тибрәләләр таллары.
Әйтерсең лә алар әйтә безгә:
«Якты булсын тормыш таңнары».

* * *

Син минсез булып, мин синсез булып,
Моңа кадәрле ничек яшәдек?
Гомер языбыз үтеп киткәнче
Бер-беребезне күреп дәшмәдек.
Нихәл итәсең, тәкъдирләр шулдыр,
Соң булса да бит, уң булсын, диләр.
Гомер җәебез булсын дәвамлы,
Булмасын анда кар-бозлы җилләр!
Син мине таптың, мин сине таптым,
Бәхет нурлары балкый йөзләрдә.
Авырлыкларга бөгелми-сынмый,
Яшәргә язсын килер көзләрдә!

## *Күңелем йолдызы*

Күктәге йолдыз булсаң син,
Иң яктысы булыр идең.
Күңелемнең түрләренә
Нурың белән тулыр идең.
Ала алмас идем синнән
Карашымны төннәр буе.
Хыялыйлар булыр идем,
Сине уйлап көннәр буе.

Бәхетемдер, син бит җирдә,
Өметемнең иң яктысы.
Сүнмәс ул, мәңгелек булыр
Мәхәббәтебез чаткысы!

## *Чәчәкле тугайда*

Ямьле җәйләрдә чыктык без
Чәчәкле тугайларга.
Бергәләшеп җырлыйк әле,
Кушылып тургайларга.
Җырларыбыз булсын безнең
Гел матурлык турында.
Иркәләнсен сөю гөле
Якты кояш нурында.
Чәчәкләрнең иң кызылын
Өзим әле үзеңә.
Җырлап кына барып җитик
Гомеребез көзенә.

## *Кәүсәриягә**

Исемнәрең генә түгел,
Җисемнәрең дә әйбәт.
Синең хакта кара эчләр
Сөйләмәсеннәр гайбәт.
Күзләреңдә таң нурлары,
Кояш назы күңелеңдә.
Кара болытлар йөзәлмәс
Безнең сөю күгендә.

---

* Кәүсәрия — җәннәт чишмәсе — кәүсәр сүзеннән.

Көнчеллектән кайберәүләр,
Сөйләмичә, нишләсен?
Син бит минем дөньялыкта
Һәрчак Кәүсәр чишмәсе.

* * *

Гомер бетсә, беркөн килеп,
Бу дөньядан күчәрмен.
Онытмасаң каберемне,
Гөлләр булып үсәрмен.
Шул гөлләргә тамган яшең
Тамырларын ныгытыр.
Мәңгелеккә аерылсак та,
Рухым кайтып җылытыр.

## *Көт!*

«Сөеклем» дип, өзгәләнеп,
Көтә торган кешем бар.
Очып кына барыр идем,
Кош юллары булыр тар.
Күкрәгемдә дәрьяларны
Кичеп чыгар көчем бар.
Бөгелеп төшмә, көт, бәгърем,
Сагынып килер кешең бар.

* * *

Тормыш бит ул — куе урман,
Адашмабыз, бергә керик.
Заман авыр, тормыш — давыл,
Ни күрсәк тә, бергә күрик.

Тормыш бит ул — чиксез дәрья,
Күкрәкләрне җилкән итик.
Матур хыял чынга ашсын,
Без шул ярга барып җитик.

## *Авыр чак*

Әллә өн бу, әллә төш бу,
Яшәлгән соңгы көннәр.
Күз яшьләре белән үтә
Йолдызлы, айлы төннәр.
Авыр чакта нишләр идем
Син булмасаң дәшергә?
Ярый әле, мәхәббәт бар,
Көч бирә ул яшәргә.

## *Көзге җыр*

Тәлгәш-тәлгәш балан җимешләре
Тирбәлдереп сыга ботагын.
Күбәләкләр булып яфрак оча,
Көз аена кердек, күр тагын!
Алтын көздә, иркәм, очраштык без,
Якынайды шулчак арабыз.
Яфрак бураннарын ера-ера,
Инде бүген бергә барабыз.
Тәлгәш-тәлгәш балан ачыларын
Күп тапкырлар авыз итәрбез.
Икәү бергә чакта бирешмәбез,
Гомеребез мул уңышлы булыр,
Көзләренә барып җитәрбез!

## *Синсез чакта*

Азга гына аерылсак та, иркәм,
Бигрәк озак булып тоела.
Көннәре дә була айлар сыман,
Көтеп-көтеп җаннар кыела.
Калтыранып, туңып уянам мин
Ялгыз түшәгемдә төннәрен.
Кулларымны җәям, юк син янда,
Сине әзли сагынып тәннәрем.
Көн яктысын, кояш нурын күрмим,
Ашауларым инде аш түгел.
Әйтерсең лә бүген түтәлендә
Җылы яңгыр көткән мин бер гөл.

* * *

Көннәрен көнлим кошлардан,
Төннәрен тулган айдан.
Сиңа гына бу гүзәллек
Килгән соң, белмим, кайдан!
Йомшак җилләрдән көнләдем,
Нечкә билле талдан да.
Бер минутка да җибәрми,
Тотам гел күз алдында.
Карашларың читкә борма,
Бел, барыбер каратам.
Көнләшә, димә, кадерлем,
Сине өзелеп яратам!

* * *

Күзләремә шикле карап,
Уфтанасың юкка гына.
Сүнәр өчен дип кермәдем
Мәхәббәтнең утларына.

Яндыр-көйдер, тик шикләнмә
Күңелемнең аклыгына.
Тыңла йөрәк тибешемне,
Ышанырсың сафлыгына!

## *Барам яннарыңа*

Саубуллашу җиңел буламы соң?!
Янә калдым юллар чатында.
Кар көртләре күмде юлларыңны,
Озак йөри язган хатың да.
Төшләремдә барам яннарыңа,
Күрешергә дип сузам кулымны.
Сагынасың бит, син дә сагынасың,
Тоеп яшим синең җылыңны.
Кар-бураннар үзәкләргә үтә,
Юк, калалмам куркып кышлардан.
Көт, бәгырем, барам яннарыңа,
Очар канат алып кошлардан.

## *Чакыр мине*

*Рәмил Мөхәммәдиев көе*

Чакыр мине яннарыңа,
Йөгереп барыйм әле.
Күзләреңә бер туйганчы
Тутырып карыйм әле.

Чакыр мине яннарыңа,
Ачып олы капкаңны.
Мәхәббәт ул — бер могҗиза,
Югалтмыйкчы тапканны.

Күзләреңә бер тутырып,
Туйганчы карыйм инде.
Яннарыңда җаннарыма
Бер рәхәт алыйм инде.

## *Сүнмәсен күңел кояшың*

*Кәүсәриягә*

Тормыш юллары бит сине
Төрле яклап сынады.
Бөгелсәң дә җил-давылга,
Синең рухың сынмады.
Көчле давыллар очрады,
Канатыңны канатты.
Ә шулай да күңелеңдә
Һәрчак якты таң атты.
Сүнмәсен күңел кояшың,
Балкысын нурлар биреп!
Тормыш авырын җырга салып,
Яшә син күкрәк киереп!

## *Кышкы кичтә*

*Фәнир Галимов көе*

Кышкы кичтә чык син урамнарга,
Һавалардан энҗе коела.
Кар бөртеге җәйге күбәләктәй,
Очып уйнагандай тоела.

Кышкы кичтә авыл урамнары
Сихри ямьгә, моңга күмелә.
Туй күлмәге кигән агачлар да
Җырлагандай була күңелемә.

Ямьле кичтә бергә булыйк әле,
Әйдә, иркәм, әйдә урамга.
Тормыш юлларыннан янәш атлап,
Каршы барыйк салкын буранга.

## *Яшә!*

*Кәусәриягә*

Ярты гасыр элек тавыш бирен,
Фани дөньяга син тугансың.
Алтын көздә тугангамы әллә,
Алтыннан да алтын булгансың.
Рәхмәтем зур сине бу дөньяга
Бүләк иткән атаң-анаңа.
Язгы ташкыннардай, йөрәгеңнән
Ургып-ургып, ярсып моң ага.
Хаклык өчен, һәрчак сафлык өчен
Яшәүләрең синең, җан атып,
Күңелләргә ятыш иҗатыңны
Кабул итә халкым яратып.
Көтсен әле алда сине тагы
Уңышларның иң-иң зурлары,
Яшә әле, озак еллар яшә,
Сибеп безгә алтын нурларың!

## *Син кирәк*

Иңнәреңә челтәр-челтәр,
Ап-ак мамык шәлләр ябып,
Гел киләсең яннарыма,
Тулпар дигән атта чабып.

Бит очларың алсуланып,
Тора пешкән алма кебек.
Чияләрдәй иренеңне
Һич тә туя алмыйм үбеп.
Хыялларда гына түгел,
Чынлыкта кил яннарыма.
Иркәм, көн дә син кирәк бит
Сагыш тулы җаннарыма!

## *Кышкы юлда*

Салкын кышлар киртә түгел
Барасы юлларыма.
Их, кыш бит, тере чәчәкләр
Тоталмыйм кулларыма.
Кар-бураннар арасыннан
Мин сиңа барыр юлда,
Нигә әле үкенергә,
Чәчәкле җәйләр алда.
Сагындым икебез йолдыз
Санаган кичләремне.
Ап-ак бураннарга төреп,
Илтәм ак хисләремне!

## *Юлга чыгам*

Ап-ак карлар яуган кышкы кичтә
Сиңа барам, сине сагынып.
Алларымда очкан энҗеләрдән
Күзкәйләрем китә чагылып.
Алларымда дистә чакрымнар,
Ә мин һаман сиңа омтылам.
Күз алдыма килеп басасың да,
Татлы хыялларда онытылам.

Юлга чыгам, юллар шундый ерак,
Чакрымнарны саныйм кайчакта.
Ә шулай да талчыгулар кая,
Сагынып көтәр кешең бар чакта?!

## *Сулмас гөлем*

Ак бураннар арасыннан,
Әйтерсең, очам бүген.
Як-ягымда бары аклык,
Сафланган күңел күгем.
Бар кайгылар онытылган,
Төшемме, әллә өнем?!
Әйе, өнем, бүген минем
Сине тәү күргән көнем.
Кыш булса да, күңелемдә
Син минем сулмас гөлем!

## *Өшемәсен гөлләр*

Тәрәз төбендәге гөлләреңне
Читкәрәк ал, кышын өшетмә.
Минем хакта юк-бар хәбәр алсаң,
Гайбәт кенә булыр, ишетмә!
Сиңа булган кайнар сөюләрем
Таң чыгында үскән саф чәчәк.
Вакытлыча гына түгел хисләр,
Яз нурына тулсын киләчәк!
Кара күңелләләр ни сөйләмәс,
Йөрәкләребезне боз итмик.
Тәрәз төбендәге пар гөлләрне
Саклыйк, иркәм, берүк өшетмик!

## *Бүләгем*

Яратам мин сиреньнәрнең
Шау чәчәкле чагын.
Бүген сиңа бүләк итәм
Чәчәкләрнең агын.

Ак сиреньнәр бүләк итәм,
Күңелдә гел аклык.
Күзләреңдә балкып торсын
Мәңге сүнмәс шатлык.

* * *

Шик тумасын күңелеңдә,
Күзләреңә туры карыйм.
Язның таң җилләре булып,
Чәчләреңнән сөеп тарыйм.

Ләйсән тамчылары булып,
Алсу битләреңә тамыйм.
Бәхет-шатлыкларың булып,
Гомерлеккә синдә калыйм.
Шикләнмә генә.

* * *

Язлар җитте инде, язлар җиткәч,
Ярларыннан ташый суларым.
Урамнарга чыгып, бер туйганчы
Авыл һаваларын суладым.

Язлар җитте инде, язлар җиткәч,
Сайрар кошлар моңын тыңладым.
Басу-кырларымны урап кайттым,
Йөрәккәем, һич тә тынмадың.
Ярсый-ярсый язгы гөрләвектәй,
Нидер эзләп йөрәк ашкынды.
Яшь йөрәккә мәхәббәтем булып,
Килеп керде язның ташкыны.

* * *

Синең белән тәүге тапкыр
Очраштык язгы кичтә.
Бу минутлар күңелемнән
Чыгарлык түгел һич тә.
Кара кашлы, бөдрә чәчле
Үсмер кыз бала идең.
Сине күргәч, әллә нигә
Тотлыгып кала идем.
Инде мәхәббәт язларын
Сагынып искә алабыз.
Яшьләр парлап узган чакта
Кызыгып карап калабыз.
Без бергә ич, ник үткәннәр
Сагындыра һаман да?
Яшьлегебезнең сафлыгы
Калган шул безнең анда!

## *Чия чәчәге*

Майлар җиткәч, чәчәк атты
Бакчабызда чияләр.
Күз яуларын алып торган
Гүзәллеккә ияләр.

Чияләрнең чәчәкләре
Хәтерләтә йөзеңне.
Инде күптән күрешмәдек,
Бик сагындым үзеңне.

Нигә әле аерым-аерым
Яшибез соң, ни өчен?
Бергә авыз итик, иркәм,
Чияләрнең җимешен!

## *Аккошыма*

Аккошлар оча һавада,
Кайтулары тизләп.
Алларыма килеп төште,
Кош мамыгы өзелеп.

Күңелемә шулай тоела —
Бу бит синең бүләгең.
Сөюебез булсын һәрчак
Аккош мәхәббәтенә тиң,
Диеп тибә йөрәгем!

## *Җырлап яшибез*

Күзләремә кара, йөрәккәем
Бары сине генә үз итә.
Сөйгән кешең белән гел аңлашып
Яшәүләргә җирдә ни җитә!
Авырлыклар, сынаулар булыр ул,
Җил-давылга яшик бирешми.
Авырлыкны җиңми генә, беркем
Бөек максатына ирешми!
Без дә, иркәм, синең белән бергә
Күп каршылык күрдек, күрербез.

Гүргә кергәндә дә елап түгел,
Җиңүчеләр булып керербез!
Язмышларга рәхмәт, кавыштырды,
Беребезгә-беребез тиңнәр без.
Бөтен авырлыкны елап түгел,
Җырлап кына, иркәм, җиңәрбез!

## *Шулдыр бәхет*

Син елмайсаң, яз кояшы балкып,
Бөтен дөньям нурга күмелә.
Кулларымда каләм, ак кәгазьгә
Күңелемнән җырлар түгелә.

Илһамланып зәңгәр күккә очам,
Канатларым белми талулар.
Нинди рәхәт тормыш юлларыннан
Киләчәккә бергә барулар!

## *Өмет белән яшим*

Шомырт чәчәкләре тагы оча.
Гүя тышта кышның бураны.
Сак белән Сок булып яшәү авыр,
Якынайтып булмый араны.
Язын сезнең яктан кошлар килде,
Юллагансыңдыр син сәламнәр.
Язмыш-тәкъдир корган гомер уза,
Синсез яшим, тоймый бер ямьнәр.
Сары сагышлардан мөлдерәмә
Тулып түгелә шул күңелләр.
Шау чәчәкләр атты тагын язын
Син бүләккә биргән ал гөлләр.

Шомырт чәчәкләре таҗы оча,
Безнең күңел кебек ак алар.
Хаклыбыз бит без дә зур бәхеткә,
Якынаер ерак аралар.

## *Китмә, иркәм!*

*Наил Шәймарданов көе*

Китәм, дисең, иркәм, китәм, дисең,
Синнән башка язлар килерме?
Язлар килер, беләм, килми калмас,
Син булмагач, назын бирерме?

Язлар белән сайрар кошлар килеп,
Талларына очып кунарлар.
Шул мизгелдә юксынудан минем
Күзләремә яшьләр тулырлар.

Ташлап китмә, берүк ялгыз итмә,
Безнең өчен кошлар кайтсыннар.
Язның сихри нурлы иртәләре
Тик икебез өчен атсыннар.

## *Якты хыял*

Син — минеке, мин — синеке,
Хыялларда без бергә.
Нигә соң бу тормыш кына
Безнеңчә түгел бер дә?

Нигә соң язмыш юллары
Төрлечә сыный безне?
Якты хыял чынбарлыкта
Калдырса икән эзне!

* * *

Күзләрдән күзләр аерылмый,
Ут инде безнең хисләр.
Табигатьнең хозур чагы,
Йолдызлы җәйге кичләр.
Иреннәр таба бер-берсен,
Елыша тәннәр тәнгә.
Эремәсәң дә эрерсең
Шулкадәр татлы тәмгә!
Талгын җилдә тибрәләләр
Яныбызда тирәкләр.
Ярыш атын хәтерләтеп,
Ярсып тибә йөрәкләр.
Гомерлек булсын, дип тели,
Бу минутны йөрәкләр.
Теләкләргә кушылгандай,
Шыбырдаша тирәкләр!

## *Нурлар кочам*

Тыңлим синең тавышыңны
Чылтыр чишмә агышына.
Әйләнмәсен генә берүк
Йөрәккәем сагышына.
Синең тавыш, синең моңың,
Дәвасы ул җаннарымның.
Гел былбылы гына бул син
Сызылып аткан таңнарымның.

Син булганга, сөю барга,
Чишмәләрнең тәмен табам.
Күр син, иркәм, мин тормышта,
Нурлар кочып, канат кагам.

* * *

Сиңа сагынып хатлар язам,
Кулларымда каләмем.
Ак кәгазьдә тәүге юлым:
«Сиңа кайнар сәламем».
Дәвам итәм, ак җирлеккә
Төшә җылы сүзләрем:
«Бигрәкләр дә сагындырды,
Иркәм, синең күзләрең».
Хатлар язам, йөрәгемнең
Биреп сиңа ялкынын.
Ялкыннарында көйдерсен,
Бирмәсен тик салкынын.
Йөрәк каным белән язам
Сөюемнең антларын.
Җаннарыма дәва булып
Килер җавап хатларың!

ЭЧТӘЛЕК

*Кәүсәрия Шафикова*

## УЙЛАРЫМ ТИРӘН УЕЛГАН

*Шигырьләр*


Теләк ....................................5
Сына ....................................5
«Балачакта дәү әнием...» ....................................6
«Балачакка кайтыр идем...» ....................................6
«Тәнемнең дә, җанымның да...» ....................................7
«Минем дә бар ул көндәлдә...» ....................................7
Чын көндәлдән ....................................7
«Җил генә түгел, бу — давыл...» ....................................8
«Сабырлыкны сары алтын, дисәләр дә...» ....................................8
«Төш күрдем: яраткан гөлем...» ....................................8
«Агачлар әле ямь-яшел...» ....................................9
«Шагыйрьнең юк зуры, бәләкәе...» ....................................9
Курчагымны эзлим ....................................10
Атлар чаба ....................................10
«Ир баласы изрәп йоклый белгәндә...» ....................................11
«Бетте инде тынычлыгың...» ....................................11
Авыл урамы ....................................12
Фаҗига ....................................12
Сөйләшү ....................................12
Ятим ....................................13
«Татар авылында туды...» ....................................13
«Уйнаштан туган бала ул...» ....................................14
Бүгенге малайлар ....................................15
«Белеп торам, сизеп торам...» ....................................15
«Шатлыктан елаган кебек...» ....................................16
Башкорт егетенә ....................................16

Давылдан соң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .17
Яшәү турында җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .17
«Сызгырып җилләрне чакырам...» . . . . . . . . . . . .18
«Авылны рәсемгә төшерәм...» . . . . . . . . . . . . . . .18
«Байлыгым бар, юк, ул байлык...» . . . . . . . . . . . .19
«Әнкәй әйткән истә генә...» . . . . . . . . . . . . . . . .19
«Сең(е)лемнең бүген туган көне...» . . . . . . . . . . .19
Бер сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .20
«Тәлгәш балан, көн буена...» . . . . . . . . . . . . . . .20
«Син бар чактагыдай үсми гөлләр...» . . . . . . . . .21
«И ходаем, күпме гомер бирдең?..» . . . . . . . . . . .21
Туган көнем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .22
Бирешмибез . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .22
Юлга чыгам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .23
Ак халатлы фәрештәләргә . . . . . . . . . . . . . . . . . .23
«Минем байлык — ике сандык...» . . . . . . . . . . . . .24
«Ходай биргән гомерен яшәп...» . . . . . . . . . . . . . .24
«Елау белән аваз салып...» . . . . . . . . . . . . . . . . .24
Бөгелмим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .25
«Бәхетсез булдым шул, диеп...» . . . . . . . . . . . . . .25
«Иң матур сүзне син әйттең...» . . . . . . . . . . . . . .26
Яшибез әле! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .26
Хыяллар яшәсен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .26
Язам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .27
«Әй, бу тормыш, суык җиле...» . . . . . . . . . . . . . .28
«Авылың матур түгел», — диде...» . . . . . . . . . . .28
«Әле күпме генә яши...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .29
Ике исемле мин . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .29
«И көне дә көне...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .30
Изгелек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .31
«Инде сабыр итә беләм...» . . . . . . . . . . . . . . . . . .31
Яшәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .32
«Картлар йорты, син тагын да...» . . . . . . . . . . . .32
Язмыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .32
Төтен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .33
Моң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .33
«Тәртипсез!» — ди торганнардыр...» . . . . . . . . . .34
«Кызарып пешкән баланны...» . . . . . . . . . . . . . . . .34
«Шатлыктан елый алмыйм...» . . . . . . . . . . . . . . . .34

«Ишетелә илаһи моң...» .35
«Каеннан өзелгән яфрак...» .36
Җиңәм .36
Күз .37
Сөю ялкыны .37
Бүләк итәм .38
Җырлар дәвалый гына .38
Матурлык әзлим .39
Кыз киткәндә .39
«Ботакта бердәнбер яфрак...» .40
«Рәхмәт сиңа, миләшле күз...» .40
«Сүрәнләнеп калды кояш нуры...» .41
«Тормыш-көнитмеш бакчамда...» .41
«Кар катыш ява яңгырлар...» .42
«Тирәкләр бәскә төренгән...» .42
Ышанам .43
Туган телне белмәгәч .43
«Ап-ак карлы февраль ае...» .43
«Матур төшме, әллә хыялмы бу...» .44
Алдану .44
Бүләгем .45
«Әлекке түгел иртәләр...» .45
«Сүзләрем бар, ничек сөйлим?..» .46
«Дару эчмә!» — димә миңа...» .46
Бәйрәмеңә киләм .47
Көткән чак .48
Кояшымны күрәм .48
Синең өчен .49
«Җилләр булып истең...» .49
Умырзая ачылган чак .50
Ышаныч .50
Сабантуйлар җитте .50
Башкортстан гөле мин .51
«Ике аккош итеп күрәм сезне...» .52
«Инә каз шул, бәбкәләрен...» .52
«Мәктәп кала, очар канатларың...» .52
«Ясалма чәчәкләр саталар...» .53
Минем кайгы .54
Йокысызлык .54
«Мин сирень түгел, яз саен...» .54

«Хиснең ялганы да кайнар...» .55
«Һәрчак әйтәм: «Бирешмимен...» .55
Өмет .56
Күрерсез! .56
Җырлар иде .57
«Сугышалар нәкъ каршыма...» .57
«Сандугачлы авылдан мин...» .58
«Кояш нурын имә сабый яфрак...» .58
«Хыяллар гел әйдәп торалар...» .59
Кошлар аңлар .59
Яшәрү .60
Яз килгәндә .60
Ат чабышы .61
«Мәхәббәт, син кошлар булып...» .62
Яз яме .62
«Тәрәзә башында чи-чи...» .63
«Авыр сүзләр ишеткәндә...» .64
Рәхмәт догасы .64
Тиң яр .64
«Мин хатын-кыз!» — диеп ничә әйтсәм дә...» .65
Көт кенә .66
Көндәш .66
«Мәхәббәтем — дәрья-диңгез...» .67
«Көрешергә насыйп булсын...» .67
«Кояшка карап үсә гөл...» .68

*Җырлар*

Минем гөлләрем .69
Бөгелмәгез .70
Төшләремдә күрәм .70
Туган як .71
Әни күзләре .72
Кабереңә килдем .73
Авылыма кайтам .73
Яфрак сибә ак каен .74
Төшләремә керерсез .74
Нигә? .76
Ятимнәр .77

Аккош .....77
Китәбез шул .....78
Игенче җыры .....79
Ак каеннар .....79
Кыңгыраулы дугалар .....80
Ак чишмә килен каршылый .....81
Кыз бала язмышы .....82
Яшьлек дустыма .....83
Язлар килер әле .....83
Кил син миңа .....84
Күрәзәче .....84
Язмыш шулдыр .....85
Бәхетле көнем булып .....86
Ай яктысы .....86
Кемне кем? .....87
Кояшлы яңгыр .....88
Мин — чәчәк .....88
Җаныма сарылгансың .....89
Китмә .....89
Сөйгән кешемә .....90
Син килдең .....90
Бәхет гөлем булып үссәңче .....91

*Рәфис Мөхәммәтдинов*

## ХИСЛӘРЕМ — ТАШКЫН

*Шигырьләр, җырлар*

Җырлап яшим .....95
«Әйткәннәре булды миңа...» .....95
Башымны имәм .....96
Егетлек .....96
«Күәс тутырып камыр изә...» .....97
Гомер телим .....98
Туган көнем .....98
Мин дә бәхетле .....99
«Җәйләрнең иң җылы, кояшлы...» .....99

Син юк, әткәй! .......................... 100
«Җиргә кадәр бөгеп агачларны...» .......... 101
Мин исән .................................. 101
Төшләремә керәсең ......................... 102
«Хәтерлим мин көзгә карап...» ............. 102
«Башындагы шау чәчәкле...» ................ 103
Сабыр безнең әниләр ....................... 103
«Февраль ае салкыннарга...» ............... 104
Әни ....................................... 105
Китмә, әнкәй! ............................. 106
«Коляскама килеп тотынды да...» ........... 106
Нишләр иде? ............................... 107
«Тирәгеннән бер сандугач...» .............. 107
Бәхетем ................................... 108
Беләсезме? ................................ 108
Авылдашым китте ........................... 109
«Әйдәләмәгез лә инде...» .................. 110
Бабайлар җыры ............................. 110
Кайт, авылдаш! ............................ 110
«Гармун уйный бер ир-егет...» ............. 111
«Миллионнар алып эшлимен...» .............. 111
Ерактагы дусларга ......................... 112
Җәйге көндә ............................... 112
«Гомерләр, и газиз гомерләр...» ........... 113
Синдә калам ............................... 113
Иртәнге җыр ............................... 114
Җәйге таң ................................. 114
Кояшлы яңгыр яуганда ...................... 115
Соңгы өмет ................................ 116
«Искиткеч бер моң агыла...» ............... 116
«Кыр кораблары басуда...» ................. 117
Шатлык .................................... 117
Кырда ..................................... 118
Җанга рәхәт ............................... 118
Бәхет нуры ................................ 119
«Бәйрәм бүген, илдә бәйрәм бүген...» ...... 120
Белем көне ................................ 120
Көзге урман ............................... 121
Саубуллашу ................................ 121

Көньякка карап уйланам . . . . . . . . . . . . . . . . . . .122
«Авылымны ямьгә күмеп...» . . . . . . . . . . . . . . . . . .122
Килен төшә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .123
Каз өмәсендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .124
Тере чишмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .124
Авылыма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .125
Теләгем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .125
Кыш килә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .126
Үкенү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .126
«Көннәр буе буран котырына...» . . . . . . . . . . . . . . .127
Түгелсен яшь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .127
«Сәгать угы уникедә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .128
Яңа ел иртәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .128
Җырың кайта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .129
«Авыл юллары таш, асфальт...» . . . . . . . . . . . . . . .130
Карлар ява . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .130
Язгы җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .131
Яңа яз җитте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .131
«Яз килгән, яз, урамнардан...» . . . . . . . . . . . . . . . .132
Туган авыл көтә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .132
Бәйрәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .133
Кайтыгыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .134
Алдыңда — зур юллар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .134
Булачак әни . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .135
«Болында каз бәбкәләрен...» . . . . . . . . . . . . . . . . .135
Язгы чәчәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .136
Кыюсез егет сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .136
Чәчәк өзгән егеткә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .137
«Йөзләреңә карап-карап куям...» . . . . . . . . . . . . . .137
Әрнеп язылган хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .138
«Минем янда сылу бер кыз бала...» . . . . . . . . . . . .138
Кызларга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .139
Гөлбакчада . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .139
«Авыл, диеп миннән көлмәсеннәр...» . . . . . . . . . . .140
«Зәп-зәңгәр иде күк йөзе...» . . . . . . . . . . . . . . . . .141
«Берәм-берәм китабез шул...» . . . . . . . . . . . . . . . .141
«Син чыгасың капка төпләренә...» . . . . . . . . . . . . .142
«Ничек кенә аны мәсхәрәләп...» . . . . . . . . . . . . . .142
«Өч күбәләк очып уйный...» . . . . . . . . . . . . . . . . .143

«Кичә генә кап-карадан идең...» . . . . . . . . . . . . . . .143
Чишмә елый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .144
Җиңәргә! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .144
«Кеше гомере, гүя, чәчәк гомере...» . . . . . . . . . . . .145
Юлдагы уйлану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .145
«Шәһәрдән авылга кайтты...» . . . . . . . . . . . . . . . . .146
Яралы күңеле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .146
Югалту . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .147
«Бер ирне кулга алдылар...» . . . . . . . . . . . . . . . . . .147
«Ир белән хатын талаша...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . .148
«Җирне тырный-тырный елый...» . . . . . . . . . . . . . . .149
«Шакыдың, рөхсәт сорадың...» . . . . . . . . . . . . . . . . .149
Эш узгач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .150
Ялгыз әби . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .150
«Бәхетле син», — диләр аңа...» . . . . . . . . . . . . . . . .151
Каргамасын язмышын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .151
«Сабаклары яшел дә соң...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . .152
«Йөрешләре бик тә сүлпән...» . . . . . . . . . . . . . . . . . .153
Урам эте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .153
Давыллы чак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .154
Сәбәп . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .155
«Зурларга охшарга теләп...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . .156
Ямьсезлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .156
Эт малае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .157
Шаһи . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .157
Бүгенге көн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .158
«Башым чатный, бир йөз грамм!..» . . . . . . . . . . . . .159
«Анасы пенсия акчасын...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .159
«Әзмәвердәй ир зарлана...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . .160
Хат килгәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .160
Күршеләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .161
Бала күңеле — далада . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .161
Ак өметем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .162
«Нинди рәхәт, дөнья белән...» . . . . . . . . . . . . . . . . . .163
«Тормышны син төзисең бит...» . . . . . . . . . . . . . . . .163
Гашыйк егеткә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .163
«Җанныны, төнге күкнеме...» . . . . . . . . . . . . . . . . . .164
Хөрмәтебез — сезгә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .164
Моң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .165

Тирәк .......... 165
«Каршыладык җәйнең тәүге таңын» .......... 165
«Син минсез булып, мин синсез булып...» .......... 166
Күңелем йолдызы .......... 166
Чәчәкле тугайда .......... 167
Кәүсәриягә .......... 167
«Гомер бетсә, бөркен килеп...» .......... 168
Көт! .......... 168
«Тормыш бит ул — куе урман...» .......... 168
Авыр чак .......... 169
Көзге җыр .......... 169
Синсез чакта .......... 169
«Көннәрен көнлим кошлардан...» .......... 170
«Күзләремә шикле карап...» .......... 170
Барам яннарыңа .......... 171
Чакыр мине .......... 171
Сүнмәсен күңел кояшың .......... 172
Кышкы кичтә .......... 172
Яшә! .......... 173
Син кирәк .......... 173
Кышкы юлда .......... 174
Юлга чыгам .......... 174
Сулмас гөлем .......... 175
Өшемәсен гөлләр .......... 175
Бүләгем .......... 176
«Шик тумасын күңелеңдә...» .......... 176
«Язлар җитте инде, язлар җиткәч...» .......... 176
«Синең белән тәүге тапкыр...» .......... 177
Чия чәчәге .......... 177
Аккошыма .......... 178
Җырлап яшибез .......... 178
Шулдыр бәхет .......... 179
Өмет белән яшим .......... 179
Китмә, иркәм! .......... 180
Якты хыял .......... 180
«Күзләрдән күзләр аерылмый...» .......... 181
Нурлар кочам .......... 181
«Сиңа сагынып хатлар язам...» .......... 182

Литературно-художественное издание

ШАФИКОВА Каусария Фидаиовна
МУХАМАДИНОВ Рафис Назипович

ВИХРЬ ЛЮБВИ

Стихи, песни

*(на татарском языке)*

Редакция мөдире *Ринат Камалов*
Мөхәррире *Динә Морзакаева*
Рәссамы *Рида Шәйхетдинова*
Бизәлеш мөхәррире *Азат Мөхтәруллин*
Техник мөхәррире *Зәйтүнә Чингизова*
Корректоры *Гөлшат Абдуллина*

Басарга кул куелды 06.11.07. Форматы 70 × 90 $^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. Банников гарнитурасы. Офсет ысулы белән басылды. Шартлы басма таб. 7,02. Шартлы буяу отт. 7,31. Исәп-нәшер таб. 6,88. Тиражы 1500 данә. Заказ № 71659.

Башкортстан Республикасының «Башкортстан «Китап» нәшрияты» дәүләт унитар предприятиесе.
450001, Уфа, Левченко урамы, 4а.

Башкортстан Республикасының «Белая река» нәшрияты» дәүләт унитар предприятиесе.
450078, Уфа, Киров урамы, 109.

КИТАП